Яңа елда өмет капкалары бәхет теләп кенә ачылсын.
Һәр йортның ишек, тәрәзенә ак канаты белән кагылсын.

Күләк көч

ГОМУМИ РАЙОН ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 52 (10691)
Чәршәмбе,
28 декабрь 2016 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1)2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы эшчеләр бистәсе, Пионерская урамы, 30)

КОТЛЫ БУЛСЫН ЯҢА ЕЛ! ГЕЛ ШАТЛЫКТАН ТОРСЫН УЛ. БӘХЕТ ҺӘМ МУЛ ТОРМЫШКА КҮРСӘТСЕН УЛ ЯҢА ЮЛ!

Рәсемдә: Иске Кулаткы эшчеләр поселогының үзәк мәйданында Кыш бабайлар һәм Кар кызлары парады.

НИЧЕК ЯЛ ИТӘБЕЗ?

Яңа ел бәйрәмнәрендә искекулаткылылар рәттән тугыз көн – 2016 елның 31 декабреннан алып 2017 елның 8 январена кадәр ял итәчәк.

1 январь ял көне – якшәмбегә туры килгәнлектән, ул 24 февральгә күчерелә. Шуңа Ватанны саклаучылар көне уңаеннан 23, 24, 25, 26 февраль көннәрендә ял итәчәкбез.

7 январь исә шимбәгә туры килә һәм ул 8 майга күчерелә. Бөек Җиңү көнендә безне 6 майдан 9 майга кадәр ял көннәре көтә.

ГОМЕР ДӘВАМЫ БУЛСЫН

Яңа елда безне котлап,
Кар ява салмак кына.
Һәр елда ул көмеш
булып,
Әкренләп чәчкә куна.

Безнең чәчләр
агарганнан,
Дөнья ямен югалтмый.
Тик бәхетләр
адашмасын,
Атласын бездән
калмый.

Еллар уза торсалар да,
Һич кимеми өметләр.
Алда барасы юллар да,
Очсыз-кырыйсыз
кебекләр.

Яңа еллар гомерләрнең
Дәвамы гына булсын!
Күңелләргә яшәү
дәртен,
Мул итеп салып
торсын!

Кыш бабайлар, Кар
кызлары,
Безгә рәхим итегез!
Ак бәхетләр һәм
тынычлык
Җиргә теләп үтегез.

Кадыйр АХМЕРОВ,
Иске Кулаткы.

ПӘНҖЕШӘМБЕ (29.12.)	ҖОМГА (30.12.)	ШИМБӘ (31.12.)	ЯКШӘМБЕ (1.01.)	ДҮШӘМБЕ (2.01.)	СИШӘМБЕ (3.01.)	ЧӘРШӘМБЕ (4.01.)
- 6	- 7	- 7	- 5	- 9	- 1	- 13
- 7	- 13	- 9	- 11	- 15	- 14	-14

Дусларым! Бәйрәм җитә бит! Бер ел буе алдык аны көтеп.
Онытыйк та иске борчуларны, Яңа елга атлыйк кыю итеп.

ЯҢАЛЫКЛАР

Дүшәмбе Россиядә, Оборона министрлыгының ТУ-154 очкычы авиаһәлакәткә очравы сәбәпле, матәм көне игълан ителде. Бу фаҗигада 92 кеше һәлак булды. Мәскәүдә "Александровский" концерт залы урнашкан бина янына чәчәкләр китерәләр, дип хәбәр итә ТАСС. Россия Президенты Указы белән 26 декабрь илдә дәүләт байраклары төшерелде, мәдәният учрежденияләрендә тамашалар һәм телерадиоканалларда күңел ачу тапшырулары, рекламалар күрсәтелмәде.

● ● ●

Россия Президенты Владимир Путин зур матбугат конференциясендә, дәүләт компанияләренең өлешен сату ил икътисады структурасын яхшырту һәм компания идарәсенең сыйфатын күтәрү өчен мөһим иде, дип белдерде.

● ● ●

Россия Президенты Владимир Путин Төркия Президенты Рәҗәп Тайип Эрдоган белән Сириядәге вазгыять һәм Россиянең Анкарадагы илчесе Андрей Карловка һөҗүм буенча фикер алышты, дип хәбәр итә Төркиянең "Анадолу" мәгълумат агентлыгы. Эрдоган һәм Путин шулай ук Россиянең Анкарадагы илчесе Андрей Карловка һөҗүм буенча тикшерүнең барышы белән канәгать булуларын җиткергәннәр.



16 января 2017 года стартует конкурсный отбор проектов развития муниципальных образований Ульяновской области, подготовленных на основе местных инициатив граждан, для получения субсидии из областного бюджета Ульяновской области. Проект по поддержке местных инициатив запущен на территории Ульяновской области по инициативе Губернатора Ульяновской области С.И. Морозова начиная с 2015 года.

● ● ●

Россия Президенты Указы һәм өлкә Губернаторы С.И. Морозов кушуы буенча 26 декабрьдә Ульяновск өлкәсендә дәүләт байраклары төшерелде, мәдәният учрежденияләрендә тамашалар һәм телерадиоканалларда күңел ачу тапшырулары, рекламалар күрсәтелмәде.

● ● ●

24 декабрьдә Губернатор С.И. Морозов Кремль чыршысында катнашырга китүче балалар белән шәхсән очрашкан иде. Бөтенроссия күләм чарада безнең өлкәдән 54 бала катнашачак. Алар арасында ел дәвамында киеренке төстә уку, спорт, сәнгать белән шөгыльләнгән балалар. Сабыйлар ял итеп, күңел ачып кайтырга бик лаек диде, үзенең чыгышында Сергей Иванович.

● ● ●

24 декабрь – Россиядә коткаручылар көне билгеләнде. Шул уңайдан өлкә Губернаторы С.И. Морозов Ульяновск өлкәсенең янгын сүндерүчеләр службасы һәм коткаручыларны, ветераннарны һөнәри бәйрәмнәре белән кайнар тәбрик итте.

УВАЖАЕМЫЕ ЖИТЕЛИ УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ! ДОРОГИЕ ДРУЗЬЯ!

Уходит в историю 2016 год. Он был значимым для Ульяновской области, и, подводя его итоги, хочу сказать всем вам огромное спасибо за любовь к родному краю, за ваше неравнодушное к нему отношение, за напряженный труд на благо своей земли.

В этом году нами сделано немало, чтобы наш регион стал успешным и процветающим, комфортным и красивым. Мы не сбавляем темпов и продолжаем идти по пути устойчивого развития, создавая себе славу авиационной, промышленной, культурной столицы. В этом году, как и в предыдущие, мы открывали новые предприятия, строили дороги, возводили культурные и спортивные центры. К нам приходят инвесторы с мировым именем, нас узнают и замечают на национальном и международном уровне. В этом году введен в строй промышленный гигант «Бриджстоун», дан старт строительству индустриального парка в единственной в России Портовой особой экономической зоны, достигнуты договоренности о создании первого в стране ветропарка, вышло на финишную прямую создание высокотехнологичного центра медицинской радиологии в Димитровграде, который совсем скоро будет готов принять первых пациентов. Мы подписали специнвестконтракт с немецко-японским концерном «ДМГ Мори», благодаря которому наши ульяновские ребята смогут внести свой вклад в процесс разработки уникальных станков и реализовывать продукцию на российском рынке.

Мы гордимся нашими победами в сельском хозяйстве – в этом году собран рекордный за последние 19 лет урожай зерна, сформирован продовольственный фонд, который обеспечивает потребность жителей области в зерне более чем в два раза. Несмотря на непростые экономические реалии, индекс производства всей продукции сельского хозяйства составил 108%.

Слагаемые нашей ульяновской мечты просты, но близки и понятны всем жителям региона. Это доступная медицина, качественное школьное образование, комфортная среда. В Год здравоохранения после длительного ремонта открыла свои двери поликлиника №2, заработали две новые детские поликлиники в Засвияжском районе и диализные центры в Новоспасском и Димитровграде. В следующем году начнёт принимать пациентов современнейший перинатальный центр на базе областной детской клинической больницы.

Выбранный нами вектор социальной политики стал залогом достойного будущего ульяновских семей, недаром более чем 13 тысяч из них решились на рождение ребенка, многие — на второго и третьего. Мы гордимся, что у нас из года в год становится больше многодетных семей: их количество вот-вот перешагнет отметку в 10 тысяч.

Мы будем и впредь создавать все условия для учёбы, занятий спортом, активного отдыха, для развития талантов и способностей наших детей. В этом году мы вошли в федеральную программу по строительству школ. Заложен первый камень в фундамент современного учебного заведения в быстроразвивающемся микрорайоне «Искра». Возобновила свою работу школа по художественной гимнастике, открылся новый спортивный комплекс в Заволжском районе и несколько ФОКов в муниципалитетах.

Мы принимаем культурные мероприятия и спортивные турниры, о которых ещё 10 лет назад никто не мог и мечтать! К примеру, чемпионат мира по хоккею с мячом, который прошел в феврале этого года, был признан лучшим за всю историю бенди. 2016 год запомнится жителям области чередой ярких достижений в культурной сфере. Ульяновская область стала главной площадкой празднования 250-летнего юбилея нашего великого земляка Николая Михайловича Карамзина. В прошлом году Ульяновск вошел в сеть креативных городов ЮНЕСКО по направлению «Литература», в этом году региону присвоен статус читающей столицы России. В Год российского кино, объявленный Президентом, мы провели масштабные ремонтные работы в сельских учреждениях культуры, открыли современные 3D кинозалы.

В наступающем году нам вместе предстоит решить немало задач, и я уверен, мы вместе достигнем любых, даже самых амбициозных целей. Новые инвестиции, новые стратегии и ошеломительные планы, новые стройки и заводы, дороги и фермы, спортивные и культурные дворцы – все это реальное будущее Ульяновской области, и все это мы сделаем для того, чтобы наши дети гордились своей родиной, хотели здесь жить, подарили нам внуков и сами стали полноправными и рачительными хозяевами своей земли!

Но все наши дерзания будут напрасны, если в погоне за свершениями мы не успеем самого главного – подарить нашим родным и близким свои тепло и любовь. Тем, кто всегда ждет нас дома с работы, кто любит и принимает нас такими, какие мы есть, кто верит в нас и поддерживает в трудные минуты, кто искренне радуется нашим победам и никогда не предаст. Семья – это самое главное, что есть у каждого из нас. Как сказал классик: «Счастлив тот, кто счастлив у себя дома». Давайте прямо сейчас скажем своим близким самые главные слова, обнимем наших детей и родителей и пожелаем нашей родной Ульяновской области счастья и процветания, новых успехов и побед ради нашего будущего, которое растет рядом с нами уже сегодня!С наступающим 2017 годом, друзья! Тепла, любви и счастья вам в Новом году!

Губернатор Ульяновской области С.И. МОРОЗОВ

С Новым годом!
Друзья!

В канун Нового года обращаюсь так ко всем жителям области, потому что этот светлый, дружелюбный праздник объединяет всех, независимо от взглядов и возраста, радостью детства и взрослой верой в лучшее.

Надеюсь, что у вас есть поводы вспомнить 12 прошедших месяцев улыбкой и добрым словом. Год принес в Россию немало трудностей, но не перечеркнул чувства гордости за нашу страну, великую, независимую, сильную.

Хорошие дела, неоспоримые успехи – общие и личные оставит уходящий год и на ульяновской земле: строились новые предприятия и дома, рождались семьи и дети, происходили открытия в науке, были достижения в культуре и спорте… Конечно, не обошлось без неприятных событий, но главным для ульяновцев стало то, что 2016-й добавил нам стабильности и миролюбия.

Немало людей считают, что жизнь оттого бывает плохой, что законы плохие. Не буду утверждать, что они совершенны, ведь безукоризненный закон - примерно то же самое, что идеальный человек. Но хочу напомнить слова, сказанные в 1845 году в Симбирске на открытии памятника историку и писателю Н.М. Карамзину: «Он не сочинял законов, но внушал к ним уважение и учил жить так, чтобы никаких законов людям не было нужно».

В 2016 году наша страна отметила 250-летие со дня рождения этого выдающегося сына России и Симбирского края. И я искренне надеюсь, что все-таки наступит время, когда люди будут жить «по Карамзину», который был противником кровавых революций и считал, что к прогрессу человечества ведет единственный путь: «Будем в среду немного лучше того, как мы были во вторник…».

А пока на смену Году Карамзина спешит 2017-й, объявленный в нашем регионе Годом предпринимательства, в России - Годом экологии. Предстоит много работы, в том числе для законодателей. Поэтому отдельное пожелание - всем депутатам Ульяновской области, всем политикам.

Уважаемые коллеги, от нас с вами во многом зависят покой, настроение и благополучие земляков. Пусть наши поступки и решения сохраняют стабильность и приближают добрые перемены на родной земле!

Дверь в наступающую Историю уже приоткрыта… Желаю, чтобы 2017 год наполнил каждый дом, каждую семью здоровьем, добротой, любовью, успехом, счастьем! Пусть будет мир – в душе и в стране!

А.А. БАКАЕВ.
Председатель Законодательного Собрания Ульяновской области.

ХӨРМӘТЛЕ РАЙОНДАШЛАРЫБЫЗ!

Чын күңелебездән сезне киләсе Яңа ел бәйрәме белән котлыйбыз. Матур традиция буларак, без бу бәйрәмне гаиләләребез, якыннарыбыз белән бергәләшеп каршылыйбыз. Үткән елга нәтиҗәләр ясыйбыз, киләчәккә планнар корабыз, Яңа елга яңа өметләр баглыйбыз.

Үтеп баручы 2016 ел безнең һәркайсыбыз өчен нинди дә булса вакыйга белән истә калачак. Кем өчендер ул шатлыклы, кайсыларыбыз өчен бәлки хәсрәтле, борчулы ел булгандыр. Барлык борчу-мәшәкатьләрне үткән елда калдырып, 2017 елны яңа планнар, якты хыяллар белән каршы аласы килә. Инде Яңа елда райондашларыбызга шулай бердәмлек белән яшәргә, югары нәтиҗәләргә ирешергә язсын, нинди хыялларыбыз бар, барысы да тормышка ашсын. 2017 елга планнарыбыз зурдан һәм без куелган максатка ирешербез, дип ышанам.

Яңа ел һәр гаиләгә исәнлек-саулык, иминлек, бәхет китерсен. Киләсе 2017 елның һәр көне районыбыз тарихына матур сәхифә булып язылсын.

Э. Ә. ГАНЕЕВ,
Иске Кулаткы районы Башлыгы.
И. А. АБЛЯЗОВ,
Иске Кулаткы район администрациясе Башлыгы.

ЗИМНИЕ КАНИКУЛЫ

На этой неделе в Ульяновской области начнется традиционная профилактическая операция «Зимние каникулы». Она стартует 29 декабря и завершится 11 января.

ПАМЯТКА ОБ ОХРАНЕ ЖИЗНИ И ЗДОРОВЬЯ, УЧАЩИХСЯ НА ПЕРИОД ЗИМНИХ КАНИКУЛ

Соблюдать правила дорожного движения в зимнее время

Быть осторожными и внимательными во время движения по дороге, особенно в вечернее время суток. Не разговаривать с незнакомыми людьми, не садиться в незнакомый транспорт. Осторожно обращаться с газовыми и электроприборами, предметами бытовой химии, лекарственными препаратами. Не подходить, не трогать руками подозрительные предметы. В случае обнаружения сообщить взрослым, в полицию. Находясь дома, не открывать дверь незнакомым людям. Всегда сообщать родителям о своем местонахождении. Не находиться на улице после 21.00 часа без сопровождения родителей. Соблюдать правила поведения в общественных местах. Помнить телефон службы МЧС: 01, 112. Не увлекайтесь длительным просмотром телевизора, многочасовой работой за компьютером. Соблюдать правила охраны жизни и здоровья во время Новогодних огоньков, не использовать хлопушки, бенгальские огни, петарды. Помнить, что во время зимних каникул ответственность за жизнь и здоровье детей несут родители: при организации и проведении новогодних праздников и других мероприятий необходимо соблюдать следующие рекомендации: запрещается применять свечи и хлопушки, устраивать фейерверки и другие световые пожароопасные эффекты, которые могут привести к пожару.

Уважаемые родители! Проводите с детьми как можно больше времени во время каникул: устраивайте совместные походы в кино, занимайтесь спортом, прививайте с детства любовь к чтению и тогда вашим детям всё реже будут приходить в голову мысли о том, что можно устраивать эксперименты с горящими спичками, зажигалками, свечами или пиротехникой.

Очень важно для взрослых – самим правильно вести себя во всех ситуациях, демонстрируя детям безопасный образ жизни и помнить, что, прежде всего, именно вы в ответе за жизнь своего ребенка.

Зульфия ДЖАМАЕВА,
консультант службы опеки и попечительства.

ШӘҺРЕ БОЛГАРДА УКУЛАРДА



ОЛЫ БҮЛӘК КУАНДЫРА

24 декабрьдә Шәһре Болгарда дин әһелләре, зыялылар, галимнәр катнашында хәнәфи мәзһәбе елы кысаларында үткәрелә торган XV «Кулаткы укулары "Аллаһы риза булсын дисәң..." фәнни-гамәли конференциясе һәм "Бәхет ул-игелек эшләүдән тәм табу" темасына "түгәрәк өстәл" утырышы булып үтте. Бу изге чарада Иске Кулаткы районыннан 70 тән артык ир һәм хатын - кыз мөселманнар катнаштылар.

Шунысы куанычлы Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Р. З. Закиров исеменнән безнең Иске Кулаткы районы Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

Билгеле, бу олы бүләкне алуда Иске Кулаткы район Башлыгы Э. Ә. Ганеевның өлеше шактый зур. Аның кайгыртучанлыгы белән районыбызның мөселманнары һәр ел изге чараларда катнашуга ирешеп киләләр. Шәһре Болгарда булып XV «Кулаткы укулары» да моның турында ачыктан-ачык сөйләде.

Ул көнне райондашларыбыз Татарстан республикасының шәҗәрәле мөселманнары белән аралашып, дини гыйлемнәрен арттырдылар. Анда районыбызның актив имамнары, Җомга мәктәпләренең мөгаллимнәре һәм мөгалиммәләре дә олы бүләкләр алуга лаек булдылар.

Көн буе барган укулар сизелми дә үтеп китте. Моның турында тәп материалны "Күмәк көч" район газетасының киләсе санында тулаем таныша аласыз.

Рөстәм АРИФУЛЛИН.

КЫЗЛАРЫБЫЗ САРАТОВТА ТАНЫЛДЫЛАР!

Күптән түгел генә Саратов шәһәрендә “Дөньяның хрусталь йөрәге” исемле балалар һәм яшүсмерләр иҗатының Халыкара фестиваль-конкурсы үтте. Әлеге конкурс иҗат ярдәмендә төрле җирләрдә яшәүче балаларны берләштерүгә, төрле илләрнең гореф-гадәтләрен саклап калуга, өлкәдә халыкара һәм милләтара мөнәсәбәтләрне нык ытуга, сәләтле балаларны эзләп табуга һәм аларда иҗат чаткысы кабызып, талантларны тамашачыларга күрсәтеп, яңа сәхнә йолдызларын кабызырга, яңа өметләр уятырга, иҗат коллективлар арасында үзара тәҗрибә алышырга, коллективлар җитәкчеләренең һәм педагогларның профессиональ мастерлыкларын үстерүгә юнәлтелгән иде.

Безнең районны югары дәрәҗәдә Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе укучысы Эльвира Деникаева, музыкаль җитәкчесе В.А. Деникаева һәм “Гөлчәчәк” балалар бакчасында тәрбияләнүче Ландыш Котлиярова, музыкаль җитәкчесе Г.Д. Хабиева тәкъдим иттеләр. Әйтергә кирәк, кызларыбыз биредә зур уңышларга ирештеләр. Эльвира Деникаева «Эстрада вокалы» номинациясендә II нче дәрәҗәле лауреат исеменә лаек булды. Ә инде нәни Ландыш Котлиярова “Вокал” номинациясендә III нче дәрәҗәле лауреат исеменә ирешә. Әлеге сәләтле кызчык күптән түгел генә өлкәдә үткән “Дуслык хоры” исемле фестивалендә катнашып, диплом белән бүләкләнде.

Саратовка баруны район Башлыгы Э.Ә. Ганеев оештырды. Фестивальдә катнашучыларыбыз һәм аларның педагоглары аңа кайгыртучанлыгы, игътибарлыгы өчен олы рәхмәтләрен белдерәләр. Әлеге уңышлар кабат балаларыбызның җыр-моңга бай, сәләтле булуларын исбатлады.

Без дә ихлас күңелдән Эльвира һәм Ландышны, музыкаль җитәкчеләрен җиңүләре белән котлап, аларга киләчәктә дә иң алдынгы булуларын, зур уңышларга ирешүләрен теләп калабыз.

Ә. ДАВЫДОВА.

БОЛЬНИЦАБЫЗДА – ЯШЬ ТАБИБЛАР

Губернатор С.И. Морозов инициативасы белән 2016 ел – Ульяновск өлкәсендә Сәламәтлек саклау елы дип игълан ителгән иде. 19 декабрь көнне регион Башлыгы катнашында “Өлкәдә сәламәтлек саклауның күркәм традицияләре” исемле медицина хезмәткәрләренең форумы үтте. Әлеге чара кысаларында Сәламәтлек саклау елына нәтиҗә ясалды.

С.И. Морозов искәртүенчә, киләсе 2017 елда Ульяновск өлкәсендә “Авыл шәфкать туташы» программасы старт алачак. Әлеге программа нигезендә 50 яшькә кадәрге, фельдшер-акушерлык пунктында эшләүче медицина хезмәткәрләренә региональ бюджеттан торак сатып алу өчен 500 мең сум күләмендә компенсацияле түләү бирелә чәк. Искәртәбез, әлеге проект регионда авыл медицина хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән. 2011 елдан өлкәбез “Авыл табибы” исемле федераль проектта катнаша, ә инде Губернатор инициативасы белән 2016 елдан “Авыл фельдшеры» программасы тормышка ашырыла.

Регион Башлыгы әйтүенчә, 2016 елдан авыл больницаларында 55 авыл табибы эшли башлады. Больницаларыбыз терапевтлар, педиатрлар, шулай ук хирурглар, эндокринологлар, неврологлар, рентгенологлар, неонотологлар һәм анестезиолог-реаниматологлар, дерматологлар белән тулыланды. “Авыл табибы” федераль программасы кысаларында авыл җиренә 270 яшь белгеч җәлеп ителде. 2017 елга өлкә бюджетыннан кадрлар потенциалын үстерүгә саламәтлек саклау тармагына 92 миллионнан артык акча юнәлтеләчәк.

Форум кысаларында Губернатор тантаналы

рәвештә намуслы хезмәтләре өчен, эшләрендә югары нәтиҗәләргә ирешүче медицина хезмәткәрләренә Рәхмәт хатлары тапшырды. Шул исәптә Иске Кулаткы район больницасының яшь табиб-рентгенологы Галина Николаевна Головина да иде. Яшь белгечкә “Авыл табибы” федераль программа кысаларында 1 миллион сумлык сертификат тапшырылды.

Әлеге программа нигезендә больницабызга Иске Кулаткыда туып үскән, Саратов шәһәрендә укып, белгечлек алган табиб-невролог А.Р. Кафизова һәм Яңа Яндука кызы, Ульяновск дәүләт университетында белем алган анастезиолог - реаниматолог Р.Р. Азизова кайттылар.

Авыл җиренә кайтучы яшь белгечләр тырышып эшкә керештеләр, йөкләнгән вазифаларын зур җаваплылык белән башкаралар, тәҗрибәле табиблардан үрнәк алалар. Эш шартлары да аларны канәгатьләндерә.

Яшь табиблар авыруларны җылы сүз, ачык йөз белән каршы алып, игътибар белән карап, дәвалауны билгелиләр, аларда өмет уяталар, файдалы киңәшләр бирәләр. Шуңа күрә дә дәваланучылар әлеге табибларны җылы кабул итеп, хөрмәт итәләр, яшь булуларына карамастан, аларга ышаныч баглыйлар.

Авыл җиренә яшь табиблар кайтып, халыкка файда китереп эшләсәләр, кадрлар җитешмәүлек проблемасы бетенләй булмас та иде.

Әлфия ЯФАРОВА.

БУДЬТЕ БДИТЕЛЬНЫ!

В целях ограничения розничной торговли спиртсодержащей непищевой продукции принято постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 23 декабря 2016 года № 195 «О приостановлении розничной торговли спиртосодержащей непищевой продукции».

Согласно указанному Постановлению юридическим лицам и индивидуальным предпринимателям предписано приостановить на срок 30 суток розничную торговлю спиртосодержащей непищевой продукции с содержанием этилового спирта более 25 процентов объема готовой продукции (за исключением парфюмерной продукции и стеклоомывающих жидкостей).

При выявлении в продаже спиртосодержащей непищевой продукции будут применены меры административной ответственности, предусмотренные статьей 14.2 Кодекса Российской Федерации об административных правонарушениях «Незаконная продажа товаров (иных вещей), свободная реализация которых запрещена или ограничена».

Помимо штрафа, статьей 14.2 КоАП предусмотрена возможность конфискации предметов административного правонарушения.

РОССИЙСКАЯ ФЕДЕРАЦИЯ
Совет депутатов муниципального образования
«Старокулаткинский район»
Ульяновской области

РЕШЕНИЕ

« 23 » декабря 2016 г. р.п. Старая Кулатка № 4/4

О внесении изменений в Решение Совета депутатов муниципального образования «Старокулаткинский район» от 15.11.2016г № 3/6

В целях приведения нормативно правовых актов в соответствие с изменениями внесенными в Налоговый кодекс Российской Федерации Федеральным законом от 03.07.2016 № 248, Федеральным законом от 6 октября 2003 года №131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Совет депутатов муниципального образования Старокулаткинский район Ульяновской области

РЕШИЛ:

1. Внести в Решение Совета депутатов муниципального образования «Старокулаткинский район» от 15.11.2016г № 3/6 «О едином налоге на вмененный доход для отдельных видов деятельности и определении корректирующего коэффициента базовой доходности К2 на территории муниципального образования «Старокулаткинский район» на 2017 год следующие изменения:

1.1. п.п.1 п.2 изложить в следующей редакции:

« оказания бытовых услуг. Коды видов деятельности в соответствии с Общероссийским классификатором видов экономической деятельности и коды услуг в соответствии с Общероссийским классификатором продукции по видам экономической деятельности, относящихся к бытовым услугам, определяются Правительством Российской Федерации; »

1.2. п.3 изложить в следующей редакции:

« Перечень конкретных видов деятельности по оказанию отдельных бытовых услуг, классифицируемых в соответствии с Общероссийским классификатором видов экономической деятельности и в соответствии с Общероссийским классификатором продукции по видам экономической деятельности, подпадающих под действие настоящего решения, определяется в соответствии с Приложением 1 к решению. Виды деятельности по оказанию бытовых услуг, не указанные в Приложении 1, не подлежат налогообложению единым налогом.»

1.3. Приложение №1 изложить в следующей редакции:

АДМИНИСТРАЦИЯ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
"СТАРОКУЛАТКИНСКИЙ РАЙОН"
УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е

«23»декабря 2016 года р.п. Старая Кулатка № 431

Об утверждении тарифа на услуги выгребной ямы,
оказываемые МУП «Благоустройство», на территории муниципального образования «Старокулаткинское городское поселение»
на период с 1 января 2017 г. по 31 декабря 2017г.

В соответствии с Жилищным кодексом Российской Федерации, Федеральным законом от 06.10.2003 № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», на основании Устава муниципального образования «Старокулаткинский район», администрация муниципального образования «Старокулаткинский район» п о с т а н о в л я е т:

1. Утвердить тариф на услугу выгребной ямы с 01 января 2017г. по 31 декабря 2017г. на территории муниципального образования «Старокулаткинское городское поселение» согласно приложению.

2. Настоящее постановление вступает в силу после его официального опубликования и распространяется на взаимоотношения, возникшие с 1 января 2017года.

3. Контроль за исполнением настоящего постановления возложить на первого заместителя Главы администрации муниципального образования «Старокулаткинский район».

Глава администрации И.А.Аблязов.

Приложение
к постановлению администрации
МО «Старокулаткинский район»
от 23 декабря 2016г. № 431

Тариф
на услугу по вывозу жидких бытовых отходов (выгребная яма), оказываемые МУП «Благоустройство» на территории муниципального образования «Старокулаткинское городское поселение»
на период с 1 января 2017 г. по 31 декабря 2017г.

№ п/п	Наименование услуги	Период	Единица измерения	Размер тарифа на услуги выгребной ямы, руб./м3
1	Вывоз жидких бытовых отходов (выгребная яма)	с 01.01.2017г. по 30.06.2017г	м3	86,00
2	Вывоз жидких бытовых отходов (выгребная яма)	с 01.07.2017г. по 31.12.2017г.	м3	90,00

АДМИНИСТРАЦИЯ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
"СТАРОКУЛАТКИНСКИЙ РАЙОН"
УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е

«23 » декабря 2016 года р.п. Старая Кулатка № 432

Об утверждении тарифа на услуги сбора и вывоза твердых бытовых отходов, оказываемые МУП «Благоустройство», на территории муниципального образования «Старокулаткинское городское поселение»
на период с 01 января 2017г. по 31 декабря 2017 г.

В соответствии с Федеральным законом от 06.10.2003г. № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации, на основании Устава муниципального образования «Старокулаткинский район» администрация муниципального образования «Старокулаткинский район» постановляет:

1. Утвердить на период действия с 01 января 2017г. по 31 декабря 2017 года включительно тариф на услуги сбора и вывоза твердых бытовых отходов, оказываемые муниципальным унитарным предприятием «Благоустройство» потребителям, в том числе населению, проживающему в частном жилом секторе, на территории муниципального образования «Старокулаткинское городское поселение» в размере 587,0 руб. м3.

3. Настоящее постановление вступает в силу после его официального опубликования и распространяется на правоотношения, возникшие с 1 января 2017г.

3. Контроль за исполнением настоящего постановления возложить на первого заместителя Главы администрации муниципального образования «Старокулаткинский район»

Глава администрации
И.А.АБЛЯЗОВ.

МӘКТӘПКӘ - ЯҢА АВТОБУС



РФ Хөкүмәтенең 2013 елгы махсус карарында мәктәп автобусларының эксплуатацияләү срогы 10 елдан артмаска тиеш диелгән. Шушы нигездә өлкә Губернаторы С. И. Морозов күптән түгел Урта Терешка урта мәктәбенә яңа автобус ачкычлары тапшырды.

Бу олы вакыйганы укучылар да, мәктәп коллективы да зур шатлык белән каршы алдылар. Әлеге автобуста балаларга утырып йөрер өчен барлык уңай шартлар тудырылган. Аның эче җылы һәм биредә уку әсбапларын урнаштыру өчен махсус киштәләр урнаштырылган. Гомумән әйткәндә, балаларның юл хәрәкәте куркынычсызлыгы өчен уңайлыклар тиешле дәрәҗәдә булдырылган.

Бүген Урта Терешка урта мәктәбендә 70 укучы белем ала. Шуларның 26 сы Яңа Терешка, 10 сы Кирюшкино авылларыннан. Мәктәп автобусында Әдһәм Ибраһимович Талипов озак еллар шофер булып хезмәт итә. Урта Терешка урта мәктәбе укучылары һәм аларның ата-аналары уңай автобус өчен Губернатор С.И. Морозовка рәхмәт җиткерәләр

Р. АРИФУЛЛИН.

Әйлән-бәйлән уйный ап-ак карлар, яңа елны көткән көннәрдә.
Җемелдиләр ак йолдызлар мени, якты йолдыз кебек төннәрдә.

ИХТИРАМГА ЛАЕК ШӘХЕСЛӘР

САВАПЛЫ ЭШ ДИП САЙЛАДЫК МӘГАРИФНЕ

Йөрәк җылысын кызганмыйча, барлык борчу-мәшәкатьләрне сабыр гына җиңеп, күңелләребезгә нур бирүче укытучыларыбыз зур хөрмәткә лаек. Мәктәпне тәмамлап, еллар үткәч тә без аларны сагынып искә алырбыз.

Иске Кулаткы урта мәктәбенең физика һәм астрономия укытучысы Фикки Сабирович Улюкаевны Иске Кулаткы районында белмәгән кеше юктыр, мөгаен. Аны укытучы буларак та, дин әһеле буларак та, ачык йөзле, җор телле кеше буларак та, бигрәк тә өлкән буын халкы, яхшы хәтерли. Юлдан узып барган бер дә таныш булмаган кеше белән дә ул исәнләшеп хәлен сорый, соравы булса аңлатып, юлын күрсәтеп, озатып кала.

Ул үзенең дүрт дистә ел гомерен балалар укытуга багышлады. 1964 елда Ульяновк педагогия институтында физика – математика факультетын укып бетергәч, Иске Кулаткы урта мәктәбенә эшкә керде һәм шунда пенсия яшенә кадәр намус белән хезмәт итте.

Бүген дә истә, мәсәлән, астрономия дәресе бара, абый дәресне башлап җибәрә дә: “Я, кызлар, егетләр бүген кем ничә йолдыз санады?” Класстагы киеренкелек юкка чыга, балалар абыйларына ачылып, үз кеше шикелле сөйләшә башлыйлар. Үзләре дә сизмәстән фән тирәнлекләренә кереп китәләр.

Аның дәресләре хәтеребезгә онытылмаслык булып кереп калды. Ул искиткеч белемле, гаять таләпчән укытучы булды. Сөйләгәндә сүзнең мәгънәсенә басым ясый, һәр әйткән сүзе урынлы, куйган таләбе хаклы иде аның. Дәресләре гаҗәеп эшлекле үтә иде. Фикки Сабирович укучыларга төпле белем бирде, үз фәненә олы мәхәббәт тудыра алды. Без, Фикки Сабировичның беренче укучылары, югары уку йортлары тәмамлап, туган мәктәбебездә укытучы булдык.

Белем бирүче буларак Фикки Сабирович Улюкаев аталарча кайгыртучан булды. Аның тормышында мәктәп һәрвакыт беренче урында иде, шулай булып калды да. Без дә аның кебек, балаларны яратып, күңел биреп эшләргә өйрәндек. Фикки Сабирович олы хөрмәткә лаек укытучы, сирәк очрый торган сәләтле, туры сүзле, гадел кеше.

Укып чыккан балаларның тормышта ничек урнашуларын да күзәтеп барырга вакыт тапты ул. Аларның уңышлары өчен ихлас шатлана белде. Мәсәлән, безнең сыйныфтан гына да укытучы һөнәрен Яңа Кулаткыдан Фирүзә Рәхмәтуллина, Акилә Мөхәммәтҗанова, Яңа Зимницадан Рәфика Абузәрова, Кәбир Бахтияров, Усть Кулаткыдан Равил Сөләйманов сайладылар, ә Ринат Хәлимов, Равил Мөрсәлимов, Абдулла Башаев, Суфия Сабитова, Шикур Иксанов, Ряхимҗан Усманов авыл хуҗалыгы тармагы белгечләре булдылар. Хәрбиләр һөнәрен Абдулла Арзуханов, Зәкәрья Бадамшин, Әбдрәшит Ибраһимов сайладылар.

Күп балалы гаиләләрдә үскән укучыларга аеруча игътибарлы иде ул. Шаянрак, “усалрак” укучыларга карата исә үзенчә бер карашы-фикере бар иде. “Сез аларны үзегездән читләштермәгез, сәләтен ачарга тырышыгыз, яраткан шөгылен үстерергә булышыгыз. Андый укучы сезне гомере буе онытмас”, – дип өйрәтә иде ул укытучыларны. Аның бу киңәшләренең ничек дөрес булганына без үз тәҗрибәбез аша инандык.

Аннары хәдисләрдә: “Мөселман кеше белемгә өйрәнеп,белгәнен дин кардәшләренә өйрәтсә, шул сәдаканың иң яхшысы булыр», - диелгән бит. Саваплы эш дип сайладык без мәгарифне, ә бәлки мәгариф безне үзе сайлагандыр. Чөнки укытучы, мөгәллим кеше һәр өлкәдән дә күпмедер дәрәҗәдә мәгълүматлы булырга тиеш.

Укытучыбыз Ф.С. Улюкаев үрнәк гаилә башлыгы. Шактый җаваплы һөнәр иясе булган Сурия апа белән алар ике бала тәрбияләп үстерделәр, һәммәсенә югары белем алырга ярдәм иттеләр. Балалары үзләре кебек үк халкыбызга тугрылыклы хезмәт итәләр. Хәзер алар уллары Наил һәм киленнәре Галия белән бик тату яшиләр.Ике оныкларына бабалары һәрьяктан үрнәк. Азат белән Ильяс бабаларын бик яраталар, ихтирам итәләр. Хөрмәт итмәслек тә түгел андый бабакайны, йомшак, сабыр үзе. Мәчеткә йөри, андагы хуҗалык эшләрен дә үз өстенә алган. “Әнвәр” мәчетенең рәисе вазифаларын башкара Фикки Сабирович. Мәчет һәрвакыт ачык, җылы, пөхтә.

Фикки Сабирович күршеләре белән дә гомере буе яхшы мөгаләмәдә яши, һәрчак ярдәмгә килеп булышып йөри, хәлләрен белешә. Кирәк икән кибеттән ипиен алып кайта. Кирәксә, кереп телевизорын я башка көнкүреш техникасын ремонтлап бирә. Кыскасы, кулыннан килмәгән эше юк аның.

Хөрмәтле укытучыбыз, сыйныф җитәкчебез! Без Сезне олы юбилеегыз белән чын йөрәктән котлыйбыз! Сезгә шушы авыр, әмма мактаулы эшегез өчен олы рәхмәт, тазалык, тынычлык, сабырлык, гаилә бәхете телибез. Һәрвакыт шулай сабыр, олы йөрәкле, чибәр булып калыгыз. Без Сезнең белән горурланабыз һәм каршыгызда баш иябез. Сезне яратып, хөрмәт итеп Иске Кулаткы урта мәктәбенең 10 “В” сыйныф укучылары исеменнән Рәфика һәм Кәбир Бахтияровлар.

САБЫР ХОЛЫКЛЫ ХАНЫМ

Тормышның һәр мизгеленнән мәгънә, матурлык табарга өйрәнгән, ашыкмый-кабаланмый гына гомер кичерүче, хезмәтеннән тәм табып яшәгән, олыгайган көнендә дә үзенең һәркемгә киләклеген тоеп яшәүче кешеләр очрый әле тирә-ягыбызда. Язмамның герое – Кирюшкино авылының хөрмәтле кешесе Зәкия Абдулхак кызы Мустафина да шундый сабыр холыклы, мактауга лаек хатын-кызларның берсе. Зәкия апа 70 ел элек Кирюшкино авылында дөньяга туа. Әйе, 70 яшь - озын гомер кебек тоелса да, көндәлек эш - мәшәкатьләр белән бер мизгелдәй сизелми генә үтеп тә киткән. Иң мөһиме-аның яшәү мәгънәсе балалары һәм оныклары тормышында ачык чагылыш тапкан.

Мәктәпне тәмамлагач ук,1963 елда, Зәкия апа туган авылының терлекчелек фермасында хезмәт биографиясен башлап җибәрә. Беренче көннән үк ул үзен гел яхшы яктан гына күрсәтә.

1965 елда Зәкия апа авылның уңган, тырыш егете – Гыйльман абый Мустафин белән матур гаилә булып яши башлый. Аларның тормышларын бизәп, бер-бер артлы ике балалары дөньяга аваз сала. Зәкия ханым авыл хуҗалыгында, терлекчелек тармагында1998 елга кадәр, лаеклы ялга чыкканчы, тырыш хезмәт итә. Намус хезмәте өчен ул өлкә, район һәм авыл җитәкчеләре тарафыннан күптөрле Мактау билгеләре, Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә. Зәкия апа күп балалы гаиләдә туып үскәнгә, бала вакытыннан ук дөньяның барлык авырлыкларын татып үсә. Бүгенге көндә ул тыныч картлык көннәре кичерә. Күптөрле туганнары аның хәлен белергә кунакка килеп йөриләр, ә ул аларны тәмле камыр ризыклары белән каршы алырга ярата. Сабыр холыклы ханым Ислам дине йолаларын төгәл үтәп, балаоныкларына догаларын укып, аларның рәхәт тормышларына куанып яши. Зәкия апаның кызы Зәлифә - гаиләсе белән Мәскәү шәһәрендә яши. Улы Гыйльфан - Түбән Кама шәһәрендә зур йөкле машина йөртүче булып хезмәт итә, хатыны Эльвира белән ике бала үстерделәр. Балалары да әниләрен сагынып, еш кына туган нигезләренә кайталар. 70 яшенә җитеп тә төсен үзгәртмәгән, ап-ак чәчләренә үз күңеледәй ак, пакъ яулык ябынган ана - кызы һәм улы өчен кадерле, иң якын кешеләре, килене өчен ягымлы каенана, оныклары өчен яраткан әбиләре. Зәкия Абдулхак кызы – гап-гади авыл хатыны. Бүтәннәрдән әлләни аерылмый, күктән йолдыз чүпләми, күпне өмет итми. Ерактан үк күренеп, балкып торган өендә бүген дә кая карама чәчәкләр, тәрәз төбе тулы гөлләр. Ходай Тәгалә аңа гомер көзләрендә рәхәттә, муллыкта, тынычлыкта яшәү мөмкинлекләрен ачкан. Картайган көнендә иң зур бәхет шул инде ул! Олы юбилее уңаеннан Зәкия апаны без дә чын күңелебездән котлыйбыз. Гомереңнең һәр мизгеле сиңа шатлык алып килсен. Бәйрәмең котлы, мөбарәк, бәхетең һәрчак түгәрәк булсын. Киләчәктә дә балалар, оныклар куанычын күреп яшәргә Ходай Тәгалә насыйп итсен.

Лилия АБДУЛЛИНА,
киптапханә мөдире.

ДИН, ӘХЛАК ҺӘМ ВӨҖДАН ИРЕГЕ

МӘҮЛИД АЕ КҮҢЕЛЛӘРНЕ САФЛАНДЫРА

Белгәнебезчә, 12 декабрьдә 1436 нчы елның Рабигүл Әүвәл ае башланды. Нәкъ шушы көнне Рабигүл – Әүвәл аеның 12нче көне (23 декабрь) Ислам дөньясында зур тантана көне. Бөтен дөнья мөселманнарының иң яраткан бәйрәмнәренең берсе – Мәүлед кичәсе. Әһәмияте буенча Кадер кичәсеннән соң икенче урында тора. Бу көнне сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) дөньяга килгән. Шул көннән башлап, Ислам нуры җәелгән. Бик күп могҗизалар пәйда булган. Үзебезчә әйтсәк, бу көн иң сөекле олугъ пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа(с.г.в.) дөньяга килгән көне дигән сүз була. Аллаһы Тәгалә аңа пәйгамбәрлек бирде, аңа Коръән индерде. Җир йөзендә Ислам динен җәелдерергә һәм бәндәләрне шул дингә өндәргә боерды. Хәзрәти Расүл Әкрам Аллаһы Тәгаләнең иң якын илчесе буларак, тугры юлны дөнья вә ахирәттә мәңгелек бәхет сәгадәткә, рәхмәткә ирешү юлын Ислам дине белән күрсәтте. Шуңа күрә аның туган көне зур бәйрәм итеп үткәрелә. Аның шәфәгатен (кыямәт көнендә яклавын) өмет итеп салаватлар әйтелә. Бу көнне “Гани” мәчете дә мөселман кардәшләребезне зур мәҗлескә җыйды. Мәчетебезнең имам-хатыйбы Рәхимҗан хәзрәт Пәйгамбәребезнең тормыш юлы турында сөйләде. Салаватлар әйтелде. Мәдрәсә мөгаллимәсе Наилә Фәйзуллина Коръән сүрәләре укып, Ислам дине юлында хәрәкәт кылып, динебезнең олы мирасын безгә тапшырып калдырган әби-бабайларыбызга, остазларыбызга, дөньядан ахирәткә күчкән хәзрәтләребезгә, абыстайларыбызга, динебезгә хезмәт кылган барча иман әһелләренә кыямәт көненә кадәр өзлексез догалар булса иде, дип багышланды. Яңа мәдрәсә бинасында 70-75 кеше сый-хөрмәт тулы өстәлләр артына утырып, кайнар ризыклар ашап, чәйләр эчеп, мәҗлесне дәвам иттеләр. “Кешегә бирелгән гомер бик кыска, беркем дә үзенә бакыйлыкка кадәр күпме вакыт бирелгәнен, кайчан үлем фәрештәсенең килгәнен белми. Һәркем үзенә хуҗа, шуңа күрә иң әүвәл калебебезгә шифалы сулыш өрүне үзебездән башларга кирәк. Һәрберебез мөмкин кадәр Аллаһы Тәгалә гыйлемен үзләштереп, изге китабыбыз Коръәни Кәримне укып, фикер йөртсәк, аятьләрдәге мәгънәләрне аңларга тырышып, тормышыбызны матурласак, вакытыбызны хәерле итеп, бушка үткәрмәсә идек. Әлбәттә, беркем дә шушы мизгелдә үк Аллаһы юлына басмый, аның гыйлеменә ябышмый. Ләкин бу тарафка әкрен- әкрен адымнар ясап, безнең, иншаллаһ, ике дөнья бәхетенә ирешүгә сәбәп булыр. Бар гамәл дә нияттән тора, максатыбызга карата - әҗәре. Әгәр дә ул изге һәм ихластан икән, Аллаһы Тәгалә дә безне ярдәменнән ташламас,”- дигән сүзләр белән Рәхимҗан хәзрәт мәхәллә халкын мәдрәсәгә белем алырга чакырды.

Бүгенге көндә мәдрәсәдә 4 группа укып йөри. Мөгәллимә Наилә Фәйзуллина аларга белем бирүдә зур тырышлык күрсәтә. Рәхимҗан хәзрәт тә, әлбәттә, белем бирүдән читтә калмый. Мәчет ишекләре һәрвакыт ачык, шәкертләрне ул шатланып каршы ала, үзе дә дәресләр бирә. Әдәп, әхлак турында аңлатмалар бирә. Рәйсә Рафикова өлкән яшьтәге апалар белән Коръән укып, мәхәлләдән бакыйлыкка күчкән әрвахларның рухларына багышлыйлар.

Аллаһы Раббыбыз эшләребезгә ярдәм, күңелләребезгә канат, җаныбызга дәрман, холкыбызга сабырлыклар бирсен. Күңел түрләребезгә, өйләребезгә, гаиләләребезгә, мәчет-мәдрәсәләребезгә, Ватаныбызга һәм барча галәмгә Аллаһы Тәгалә Хак муллык вә сәгадәт тынычлыклар насыйп әйләсен. Бәйрәмнәребез мөбарәк булсын!

Гөлсинә РАФИКОВА,
“Гаилә” үзәге
психологы.

ТӘБРИКЛӘҮЛӘР КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

Мосеевка авылында тормыш итүче Шәүкәт Дәүләтшович ДАВЫДОВ 2 январьда 60 яшьлек юбилеен билгели. Сабыр холыклы, мәрхәмәтле, ярдәмчел, кадерледән-кадерле тормыш иптәшем, әтиебез, бабакаебыз, улым, киявебез, кодабыз!

Шушындый зур һәм якты бәйрәмең көнендә без сиңа ихлас котлауларыбызны юллыйбыз. Син бит безнең өчен иң якын кешебез. Син булмасаң без оясыз кош, моңсыз җыр, җырсыз сандугач кебек яшәр идек, тормышыбызның яме дә, тәме дә булмас иде. Безнең өчен һәрчак олы җанлы, киң күңелле булып калуың өчен мең рәхмәт сиңа. Без синең белән горурланабыз. Син гомер буе безнең өчен тырыштың, безне кеше итү өчен китте бөтен көчең, шуңа да без сиңа рәхмәтлебез.

Җир йөзенең бөтен матурлыгын,
Килә сиңа бүләк итәсе.
Дөньядагы матур сүзләрнең дә,
Иң җылысын килә әйтәсе.

Матур теләкләр белән тормыш иптәшең Венера Камиловна, әтиең Дәүләтша Исхакович, каенанаң Сания Юнусовна, каенатаң Камил Солтанович, кызларың Гөлназ, Әлфия, Гөлфия, кияүләрең Рөстәм, Руслан, Динар, оныкларың Әминә, Диана, Рәсүл, Динә, Лиана, кода-кодагыйларың: Равилә-Мансур Бахрановлар, Фәридә-Марс Яфаровлар, Әлфия-Дамир Кузахметовлар, Давыдовлар, Заитовлар, Сабитовлар, Хамзиннар гаиләләре.

Мосеевка – Иске Кулаткы – Павловка – Татар Шмалагы – Евлейка – Ульяновск – Мәскәү.

Мосеевка авылында яшәүче Динар ТЮКАЕВКА 28 декабрьдә 5 яшь тула. Сөекле улым, кадерле оныгым, яраткан энем!

Сине туган көнең белән котлыйбыз һәм исәнлек-саулык, озын гомер, тәүфыйклы, иманлы, акыллы, мәрхәмәтле булып үсүеңне телибез. Киләчәктә нур сибүче йолдыз булып, безнең күңелләрдә мәңге балкысаң иде.



Котлы булсын туган көнең,
Күзләреңдә нурлар сүнмәсен.
Бүгенгедәй шат елмайган йөзең
Кайгы чаткылары күрмәсен.
Син яшәгән гүзәл җирдә
Гел аяз булсын күгең.
Бәхетле балачак, озын гомер
Телибез сиңа бүгән.

Иң җылы теләкләр белән әниең Лилия, бабаң Хамзя, апаң Диана, абыең Марат.

Мосеевка.

Яңа Терешка авылында гомер итүче Роза Закировна ФӘЙЗУЛЛИНАГА 4 январьда 75 яшь тула. Кадерле һәм хөрмәтле әниебез!

Сине чын күңелебездән юбилеең белән котлыйбыз. Ата-ана һәм туган кадерен белергә өйрәтүең, һәрвакыт якыннарыңны кочак җәеп каршы алуың өчен бик зур рәхмәт сиңа. Син безнең өчен һәрвакыт олы җанлы, киң күңелле кеше, таныгычыбыз, киңәшчебез, җылы кояшыбыз. Ягымлы, йомшак күңелле булганың өчен олы рәхмәт сиңа. Сиңа җәйге кояш нурларыдай аяз көннәр, сөенечле иртәләр, җан тынычлыгы, саулык-исәнлек, озын гомер, ак бәхетләр телибез. Безне сөендереп озын-озак яшә!

Котлы булсын туган көнең,
Юлларыңа гөлләр сибелсен.
Гомерләрең, кадер хөрмәтләрең
Бәхет-шатлыкларга күмелсен.
Ходай сиңа сәламәтлек бирсен,
Бездән сиңа шундый теләкләр.
Синең ягымлы йөзеңне күреп,
Куансыннар безнең йөрәкләр.

Иң изге теләкләр белән кызларың Гөлфия, Фәридә, улларың Вильдан, Гыйльман, кияүләрең Абдлкадыйр, Рәис, киленнәрең Румия, Венера, кода-кодагыйларың.

Яңа Терешка – Яңа Зимница – Ульяновск – Яңа Лава – Казан.

Кадерле һәм сөекле әбекәебез Роза Закировна ФӘЙЗУЛЛИНА!

Без сине матур юбилеең белән тәбрик итеп, иң изге, иң якты теләкләребезне юллыйбыз. Сиңа булган рәхмәтләребезне, күңелдәге теләкләрне сүз белән әйтеп бирергә мөмкин түгел, алар иксез-чиксез. Син безнең таныгыч та, ышаныч та, саклаучыбыз да. Безгә күрсәткән игелекләрең уйлап та, әйтеп тә бетерерлек түгел. Барысы өчен дә зур рәхмәт сиңа. Ходай Тәгалә кылган игелекләреңне күреп, сиңа исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, чиксез шатлыклар насыйп итсен.

Рәхмәт синең шәфкать тулы йөрәгеңә,
Рәхмәт ару-талу белмәс беләгеңә.
Рәхмәт хастәр белән караган күзләреңә,
Юаныч һәм шатлык биргән сүзләреңә.
Син булганда без бик бәхетле,
Синең белән дөнья бик тыныч.
Саулык белән, шатлык белән үтсен һәр көнең.

Изге теләкләр белән оныкларың Рамис-Эльмира, Рамил-Рамилә, Гөлчәчәк, Рәмзия, Ринат, Азалия, Розалия, оныкчаларың Айзель, Резедә, һәм Розалия.

Яңа Терешка – Яңа Зимница – Ульяновск – Яңа Лава – Казан.

Урта Терешка авылында гомер итүче Мөнир Закирович ШӘМИОНОВ 31 декабрьдә 75 яшьлек юбилеен билгели. Иң кадерле кешебез - яраткан әтиебез, бабакаебыз!

Без сине матур юбилеең белән тәбрик итеп, иң изге, иң якты теләкләребезне юллыйбыз. Безне кадерләп үстереп, яратып-сөеп, аталарча кайгыртканың, гаделлеккә өйрәткәнең өчен зур рәхмәт сиңа, әти. Син, әти, безнең өчен һәрчак олы җанлы, киң күңелле кеше, таныгычыбыз, ышаныгычыбыз, киңәшчебез, җылы кояшыбыз, рух чишмәбез, яшәү өлгебез. Сиңа булган рәхмәтләребезне, күңелдәге теләкләрне сүз белән әйтеп бетергесез түгел, алар иксез-чиксез. Сиңа гомернең иң озынын, бәхетнең иң зурысын, шатлыкларның иң олысын телибез. Синдәй якын кеше булганга, без бик бәхетле.

Төрле чакны күргәнсеңдер, әти,
Йөрәгеңдә күптер яра да.
Киңәшчебез, терәгебез булып,
Озак яшә безнең яныбызда.

Иң изге теләкләр белән кызларың Мөнирә, Фирүзә, улың Марс, кияүләрең Рәшит, Марат, киленең Рузалия, 9 оныгың һәм 7 оныкчаң.

Урта Терешка – Суруловка.

Мосеевка авылында гомер кичерүче Илдус Рәшитович СӘЛИМОВ 1 январьда 50 яшьлек юбилеен каршы ала. Кадерле улым, яраткан тормыш иптәшем, әтиебез, хөрмәтле киявем!

Сине чын күңелебездән юбилеең белән котлап, йөрәкләребездән чыккан иң изге теләкләребезне юллыйбыз. Сиңа исәнлек-саулык, түземлек, сабырлык, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр телибез. Ходай Тәгалә сиңа хәерле озын гомер, җан тынычлыгы, иман байлыгы бирсен.

Котлы булсын, әти, юбилеең,
Шатлык балкып торсын йөзеңдә.
Безнең өчен бик тә кадерле син,
Рәхмәт яусын барысы өчен дә.
Шатлык сөенечләр ташламасын,
Кайгы-борчу ишек какмасын.
Ходай Сине барыбызга өчен
Күз карасы кебек сакласын.

Иң изге теләкләр белән әниең Мөнирә Хәсәновна, тормыш иптәшең Венера Миралиевна, кызың Эльвира, киявең Илзар, улың Эльнар, каенатаң Мирали Хәсәинович һәм барлык туганнарың: Байбиковлар, Әбдрәшитовлар, Кузахметовлар, Ибраевлар, Алиевлар, Сагитовлар гаиләләре.

Мосеевка – Ульяновск – Тольятти – Казан – Чарджоу – Калмаюр – Павловка – Евлейка.

Кадерле абыебыз Илдус Рәшитович СӘЛИМОВ!

Без сине юбилеең белән котлап, гомернең иң озынын, бәхетнең иң зурысын, шатлыкның иң олысын телибез. Гаилә тигезлеге, җан тынычлыгы, эшеңдә зур уңышлар, күтәренке кәеф юлдаш булсын. Һәрвакытта да шулай шат, көләч йөзле, изге күңелле, ихтирамлы, игътибарлы булып, балаларыңның, якыннарыңның игелеген күреп, мул тормышта яшәвеңне Ходай насыйп итсен.

Салкын карлы кышта тусаң да син,
Яз кояшы һәрчак күңелендә.
Һәрвакытта йөзең көләч булсын,
Балкып яшә гомер-гомергә.
Теләкләрнең кайсын теләсәк тә,
Аз булыр күк синең хөрмәткә.
Аяз булсын мәңге күңел күгең –
Без калабыз шушы теләктә.

Иң җылы теләкләр белән энең Иршат, тормыш иптәшең Гөлфия, балалары Альбина, Алмаз.

Мосеевка.

Кадерле кодабыз, сөекле әтиебез Илдус Рәшитович СӘЛИМОВ!

Без сине чын күңелдән гомер бәйрәмең белән котлыйбыз. Сиңа исәнлек-саулык, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр телибез. Олы юбилеең мөбарәк, ризык тулы өстәл әсте түгәрәк, гомер юлың сикәлтәсез һәм куанычлы булсын. Кылган игелекле гамәлләрең үзеңә меңе белән әйләнеп кайтсын. Йөзеңдәге шатлык нурлары беркайчан да сүнмәсен. Гаиләдә гел шулай үрнәк әти, яраткан тормыш иптәше, хөрмәтле кода, туганнарыңның таянычы булып кал.

Матур таңнар атсын синең өчен,
Тормыш дәртең бер дә сүнмәсен.
Һәр яңа көн сиңа нык исәнлек
Һәм гомерлек бәхет өстәсен.
Котлы булсын синең юбилеең,
Сәламәтлек – бездән шул теләк.
Саулык булса, җирдә бар да була,
Бу дөньяда тагын ни кирәк?!

Матур теләкләр белән кодаң Рөстәм Касымович, кодагыең Наилә Рәхимҗановна, киявең Илзар, кызың Эльвира, уллары Рафаэль, тормыш иптәше Динара белән, карт кодагыең Сания Исхаковна, кодачаларың Рәкибә, Равилә, Гөлфия, Асия гаиләләре белән.

Мосеевка – Иске Кулаткы – Мәләкәс – Ульяновск – Мәскәү.

Якын кешебез, кадерле туганыбыз Илдус Рәшитович СӘЛИМОВ!

Без сине истәлекле туган көнең белән котлыйбыз. Алдагы тормышыңда да нык исәнлек, күңел тынычлыгы, гаилә иминлеге, ак бәхетләр телибез. Гомер юлың якты кояш кебек булсын, һәрбер көнең куаныч, яшәү яме, дөнья иминлеге белән тулып торсын. Рәхмәтләргә һәм рәхәтләргә төренеп яшә. Безнең өчен һәрчак олы җанлы, киң күңелле булып калуың өчен рәхмәт сиңа. Без сине чиксез хөрмәт итәбез!

Һәрчак шулай яшьлек дәрте синдә
Янып торсын җәйге учактай.
Саулык, байлык, күп шатлыклар
Чиксез булсын язгы офыктай.

Изге теләкләр белән Мөнир Расимович, Гүзәлия Фаиловна, уллары Марсель, кызлары Ленара, кияүләре Илнур, оныклары Амир, апаң Рәкия Лөкмановна, тормыш иптәшең Расим Искәндәрович.

Мосеевка – Ульяновск.

Хөрмәтле Илдус Рәшитович СӘЛИМОВ!

Мосеевка авылында эшләп килүче “Поляна” крестьян-фермерлык хуҗалыгы җитәкчесе Р. К. Хәбибуллин һәм тулаем коллектив Сезне истәлекле 50 яшьлек юбилеегыз уңаеннан чын күңелдән тәбрик итәләр. Илдус Рәшитович хуҗалыкта озак еллар дәвамында механизатор булып эшли. Үз вазифаларын ул тырышып, җиренә җиткереп башкара. Гомер бәйрәмегез уңаеннан Сезгә саулык-сәламәтлек, гаиләгездә иминлек, бәхет, тигез тормыш телибез. Һәрчак шундый ачык йөзле, тырыш, киң күңелле, ярдәмчел булып калыгыз. Бәхеткә төренеп озак яшәгез, якыннарыгызның ихтирамы гел юлдаш булсын. Фидакарь хезмәтегез өчен олы рәхмәт Сезгә!

Котлы булсын синең юбилеең,
Гомерең үтсен шатлыкта.
Бүгенгедәй шат елмайган йөзең,
Шатлык өсти барыбызга да.
Йөрәгеңә җыйган яхшылыклар,
Изгелекләр булып кайтсыннар.
Туар таңнар алып килсен сиңа,
Сәламәтлек, бары шатлыклар.

Иске Кулаткы эшчеләр бистәсендә гомер итүче Фикри Сабирович УЛЮКАЕВКА 2 январьда 80 яшь тула. Кадерледән-кадерле тормыш иптәшем, сөекле әтиебез, яраткан бабакаебыз, хөрмәтле кодабыз!

Сине ихлас күңелебездән олы бәйрәмең белән тәбрик итәбез! Ныклы сәламәтлек, шатлык-куанычлар, күктәге кояшның тик сихәт нурларын гына сибүен, күңел тынычлыгы, сөенечләргә куанып яшәвеңне телибез. Туачак таңнарың тыныч, килер көннәрең шатлык белән тулып торсын. Син олысына да, кечесенә дә кешелекле, ярдәмчел, игелекле һәм абруйлы киңәшче, сабыр холыклы, олы йөрәкле, шуңа күрә дә туганнарың һәм дусларың арасында ихтирамга лаек. Без сине чын йөрәктән яратабыз!



Кешелекле бит син, олы җанлы,
Ярдәмле син дуска, туганга.
Синнән газиз кеше белмибез бармы,
Без бәхетле тик син булганга.

Изге теләкләр белән тормыш иптәшең Сурия Имадиевна, улың Наил, киленең Галия, оныкларың Азат, Ильяс, кода-кодагыйларың Асия һәм Рөстәм Арифуллиннар.

Иске Кулаткы.

Иске Мостякта гомер итүче Рафаэль Җиганшевич МОХАМЕДОВКА – 60 яшь. Кадерле кешебез – яраткан энебез!

Җир йөзендәге иң изге теләкләр, йөрәктәге иң кадерле, гүзәл хисләр белән сине олы юбилеең-туган көнең уңаеннан котлыйбыз. Сиңа бәхетнең иң зурысын, шатлыкларның иң олысын, исәнлекнең иң ныгын, гомернең озынын теләп калабыз. Якыннарыңның җан җылысын сизеп, бәхеттә яшәргә язсын сиңа.



Озын гомер бирсен Ходай Тәгалә,
Тыныч булсын һәрчак җаннарың,
Кочак-кочак бетмәс куанычлар
Төяп килсен туар таңнарың.

Изге теләкләр белән апалары Роза, Рәшидә, Наилә, киленнәре Нәҗия гаиләләре белән, абыйсы Ришат гаиләсе белән.

Иске Мостяк – Самара – Иске Кулаткы.

Иске Мостяк авылында гомер итүче Рауза Абдулхаковна НАСЫРОВА 5 январьда 65 яшьлек юбиллен билгели. Кадерле тормыш иптәшем, газиз әниебез, яраткан әбекәебез!

Без сине чын күңелдән олы юбилеең белән котлыйбыз. Әниебез, Аллага шөкер, безне сөендереп, якын киңәшчебез булып барыбызны бергә туплап, безнең арада яши, һәрберебезнең тормышы турында кайгырта. Киләчәктә дә Ходай безне бу бәхеттән аермасын. Безне, балаларыңны, сау-сәламәт итеп үстергәнең, тырышып эшләргә, кешеләрне хөрмәт итәргә өйрәткәнең өчен мең-мең рәхмәт сиңа, кадерлебез! Яныбызда синдәй игелекле, сабыр, төпле киңәшләре белән ярдәм итәрлек кешебез булуга без чиксез бәхетле.

Сәйкемле карашың кояшка тиң,
Бар тормышны нурга күмәсең.
Бу дөньяның барлык хикмәтләрен
Бары тик син генә беләсең.
Тормышта гел ярдәм итеп тора
Зирәк киңәшләрең, җылы сүзең.
Иркәлисең, яратасың, юатасың,
Тыңлыйсың да, аңлыйсың да үзең.

Җылы теләкләрең белән тормыш иптәшең Таһир, улың Илдар, кызың Наилә, киленең Гөлнара, киявең Фәнис, оныкларың Айрат, Алина, Алеся, Реналь.

Иске Мостяк – Тольятти.

Иске Яндука авылында гомер кичерүче Әлфия Әбдрәшитовна ТИМЕРБУЛАТОВА 28 декабрьдә 50 яшьлек юбилеен каршы ала, ә инде 27 декабрь көнне әтиебез белән матур гаилә булып яши башлауларына да 30 ел тулды. Хөрмәтле тормыш иптәшем, кадерле әниебез, әбекәебез, яраткан киленебез!

Сине күркәм юбилеең белән котлап, иң изге теләкләребезне юллыйбыз. Рәхмәт әни, әти белән безне яхшы кешеләр итеп, сөеп үстердегез. Тормышта күпләргә үрнәк гаилә корып, яшәү өчен көч биреп яшисез. Барлык кылган изгелекләреңә, ярдәмнәреңә, бөтен гомереңне «балаларым, оныкларым, туганнарым» дип, өзелеп яшәгәнең өчен тирән рәхмәтлебез. Син үзеңнең күңел җылысын һәркемгә дә җиткерәсең, төпле киңәшләрең белән ярдәм итәсең. Кунакчыл йортыбызда һәрвакыт тәмле ризыклар әзерләп, мул табын белән кем генә килсә дә, елмаеп каршы аласың, ихтирам күрсәтеп, озатып калась

Котлы булсын, әни, туган көнең,
Озак яшә, бул син бәхетле.
Яныбызда син булганда гына
Табып була олы бәхетне.
Тормыш юлың һәрчак балкып торсын,
Ягымлы, шат булсын күңелең.
Озын гомер, сәламәтлек белән
Бәхет-шатлыкта үтсен гомерең.

Сине чиксез яратып, хөрмәт итеп, тормыш иптәшең Илдус Абдулхакович, кызың Юлия – Алексей, улың Риво – Марина, каенатаң Абдулхак Алимҗанович, каенанаң Фәһимә Якуповна, оныкларың Николай, Ләйсән, Элиза һәм Марсель.

Иске Яндука – Тольятти – Саратов.

Хөрмәтле Гөлфия Җәрүлловна ХАМЗИНА!

Мәгариф хезмәткәрләренең район профсоюз оешмасы һәм Иске Зеленай урта мәктәбе коллективы Сезне матур юбилеегыз - 50 яшь тулу көнегез белән чын күңелдән котлыйлар. Киләчәктә бәхетле озын гомер, чиксез шатлыклар, корычтай исәнлек телиләр. Алдагы тормыш юлларыгыз гел матур һәм якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт саф, якты нурларга төренсен. Фидакарь хезмәтегез өчен олы рәхмәт Сезгә.

Тәбриклибез юбилеегыз белән,
Очрамасын Сезгә киртәләр.
Саулык, бәхет, озын гомер,
Алып килсен нурлы иртәләр.

Яңа елның һәрбер сәгать-көне ап-ак кардай якты, ак булсын.
Кыш бабайның кызыл капчыгында барыбызга бүләк табылсын.

БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

ÊÖÒÅÏ ÓÇÃÀÍ ÃÎÌÅÐ

Повесть

Зифа Кадырова

- Борчылма, Самат, ул берни дә күрмәячәк, аның миндә кайгысы юк.

- Ни булды сиңа, Рушания, ничек күрмәсен ди, ул бит синең өчен үләй язып тора, оныттыңмы әллә тегене кәнне?

- Хәзер аның эше күп, - диде.

Хәзер инде ул аны эзләми дә, борчылмый да, ул аны башка яратмый да. Кабат йөрәкне чеметтереп авыртырга, ашказаны өсте кисәргә тотынды. Юк, ничек тә өйгә чаклы җитәргә кирәк, тик хәле бетүен тоеп, әле яңа гына Ильич биргән даруны авызына кабып җибәрде. Ахрысы, бу инде яңа чиредер, ничек каты итеп башы да авырта. Күз кырые белән генә күзәтеп барган Самат машинаны юлдан читкә борды, җайлырак урын табып, Кама елгасы буена яр читенә туктатты, чыгып, машинаның ишеген ачты.

- Мә, су эч, - дип, шешә белән су бирде. Рушания йотлыгып суга ябышты, әйтерсең, чүлдә өч көн сусыз утырган. Аңа җиңел, рәхәт булып китте.

- Әйдә, әзрәк яр буйлап йөрибез, алайса өеннән чыкмыйча берүзең ятасың. Исән кеше дә акылдан язар. Сал аяк киемнәреңне, - үзе дә аяк киемнәрен салып, чалбар балакларын бөкләде. - Әйдә, яр буйлап суда йөрибез, култыкла мине.

Алар шулай шым гына яланаяк яр буйлап икәү атладылар. Кояш нурлары җылыткан күл суы, аяк астындагы йомшак вак ком, аякларны иркәләп су чайкала. Әйтерсең, вак дулкыннар да шатлана, яннарына килүчеләр булганга. Алар да шаяра, артка китәләр дә, кабат килеп бәреләләр, шыбыр-шыбыр көлешәләр төсле. Акрын гына искән җил йомшак кына чәчләреннән сыйпап уза, әйтерсең, юатырга, тынычландырырга тели. Нинди рәхәт икән болай йөрү, бөтен табигать хәленә керә, юата-иркәли, берни аңлатуыңны да сорамый. Барасы да, барасы иде шулай. Рушания беразга туктап, су өстенә карап торды: иксез-чиксез дөнья, күк йөзе чалт аяз, галәм киңлеге, ул шушы чиксез галәмнең бер тузаны гына. Самат берсүзсез аны кирегә борды, алар инде машинадан хәйран ерак киткәннәр иде.

- Нинди сихри көч бар бу табигатьтә? Без аның бәндәләре көннең-көнгә ниндидер вак-тәяк эш белән чабып, шушы Ходай биргән матурлыкны да күрмибез, аралашмыйбыз. Ходайның кодрәте киң, һәркөн туган якты көнен шулай тиеш дип кабул итәбез, Ходайга рәхмәт әйтергә дә онытабыз. Без Ходайны инде җәлләр-аңлар кешебез калмагач кына искә төшерәбез.

Рушания туктап су өстенә текәлде, беркемгә әйтә алмаган, авыр йөк булып көн-төн йөрәкне талаган серләрен шунда бушатып калдырырга теләде. Иреннәре калтырап, күзләреннән яшь атылып чыкты, Саматның беләгенә ныграк тотынды. Самат аны туктатмады, тыймады. Рушаниянең борын яфраклары буйлап яшь бөртекләре тәгәрәде, күз яшьләре Кама суына тамды да, дулкыннар белән бергә кушылып агып китте. Тагын азрак җиңеллек килгәндәй булды. Самат та үзалдына нәтиҗә ясады ахрысы, эш чирдә генә түгел, әгәр дә уйлаганы шул булса, бик тә кызганыч, мондый авыр чакта якының янында булуга ни җитә. Ә ул китә дә бара... Болай булса эшләр харап иде, юкка гына кеше шулай кинәт бетерешми.

- Эх, Рушания дускаем, ничекләр генә ярдәм итим соң?

Икенче көнне төштән соң Самат кабат килде, Рушания кичә Ильичның кайдадыр чакыруына әһәмият бирмәде. Кайда да булса бару, кем беләндер очрашу, сөйләшү аның өчен газап кына иде. Самат килгәч тә, юк-юк, дип карышып караса да, Самат ай-ваена карамыйча, киендереп алып чыгып китте. Алар бер кечкенә кафе кырына килеп туктадылар. Рушания утыра торган ишекне ачып:

- Бик озак көттердегез, - дип кемдер кулын сузгач, Рушания башта үрелеп карады, таныгач кына кулын бирде. Каршысында моңача Рушания әле белмәгән кеше басып тора иде. Өстендә гади генә җәйге җиңел костюм-чалбар, башкалардан берни белән дә аерылмый торган гади генә кеше иде. Ул үзенең эш урынында гына бөтен чирле кешенең Алласы, ул кай тарафка үтсә дә, аңа йөзәрләгән күз өмет белән ияреп йөри, һәрбер әйтеләсе сүзен йотарга тора, ә монда аны белүче юк, ул бүген шушында арлы- бирле йөрүчеләрнең берсе генә. Илья Рушаниянең кулын ычкындырырга ашыкмады, йомшак кына елмаеп:

- Әгәр килмәсәгез, мин шунда утырып елый идем, - дип елмайды, үзе берсүзсез аны җитәкләп каядыр эчкә тартты. Бу кафеның эчке ягы бик мөлаем һәм күркәм генә урын булып чыкты, акрын гына ниндидер музыка уйный. Илья аны почмактагы бер өстәлгә алып килде.

- Менә монда тыныч урын, - дип Рушаниягә урындык күрсәтте, алар кара-каршы утыруга, яннарына ашыга- ашыга бик чибәр бер ханым килеп басты.

- Гафу итегез соңга калуыма, - дип Илья белән яңакка-яңак терәп исәнләштеләр. Рушания бөтенләй югалып- аптырап калды таныш булмаган кешеләр арасында.

- Менә таныш булыгыз, бу - Рушания Бариевна Захарова, - дип Илья икесе уртасына утырды. - Ә бу - Анна Яновна, минем пациенткам. Әйтергә кирәк, бик күптәнге. Без инде биш елдан артык Илья Ильич белән аерылгысыз дуслар дияргә кирәк, (үткән елларны ай саен очраша идек, хәзер инде ярты елга бер. Әлегә Ходай саклап килә, мин аны тыңлыйм, ул мине дәвалый. Сез сөйләшеп утырып торыгыз, мин берәр нәрсә алып килим эчәргә, - дип Илья Ильич торып китте.

-Гафу итегез, исемегез исемдә калмады.

- Рушания, Рая дисәгез дә була.

- Рая, сезнең нинди диагноз? Хәер, Илья кешегә беркайчан әйтми, кешенең гомере өчен ахыргача көрәшә, өмет калдыра. Минем бер күкрәгем протез, моннан биш ел элек Илюша төбеннән кисеп атты, башта, белсәгез, ничек авыр булганын. Ул моны шундый итеп әйтте, әйтерсең, күлмәк итәген генә кисеп ташлаганнар. Рушания башта агарып китте, аннан югалып калды. Бу хатын таныш булмаган кеше алдында шулай җиңел генә чирен ачып салды, әйтерсең, алар кафеда түгел, ә больницаның бер палатасында яталар. Рушания болай җиңел ачыла торган кеше түгел иде шул.

- Ә ирегез ничек кабул итте бу хәлне?

- О-о, ирме? Менә шул ир аркасында килеп чыкты да инде. Ул мине ике бала белән ташлап китте, мин шундый төшенкелеккә бирелдем, ә чир, әйтерсең, шуны көтеп кенә торган. Бәла бер килсә килә ул, аны куып җибәреп тә, елап җиңеп тә булмый. Илья коткарды мине, чирдән генә түгел, үз-үземә ышанырга ярдәм итте. Үз-үзеңне җәлләп, елап утырган кешене кем яратсын - кызганудан башкага ярамыйсың. Кызганыч кеше - кызганыч кеше инде ул, ничек кенә борсаң да.

- Менә, кызлар, мин сезгә шундый тәмле эчемлек алып килдем, - дип бер поднос белән бер ак аракы, салатлар китереп куйды, өчесенә дә аракы бүлеп салды. - Әйдәгез, күмик шул чирләрне, - дип салган рюмкасын күтәрде.

- Әйе шул, Илюша, чукынып китсен чирләре дә, безне яратмый ташлап киткән ирләре дә, - дип көлде Анна.

Алар шулай бик озак сөйләшеп утырдылар. Рушания да онытылып аларны тыңлады, куйган аракыга гына кагылмады, ул эчсә дә, җиңел винолар гына эчә иде. Мондый каты аракы кебек нәрсәләргә якын да килгәне булмады. Моны сизеп утырган Ильич:

- Рушания, сезгә баллы винолар эчәргә ярамый, әз генә аракы эчеп куй, ул азрак шикәрне дә төшерә, - дигәч, Рушания ирен генә тидереп куйды, тик эчә генә алмады.

- Яратмыйм, бигрәк тәмсез, - дип, рюмкасын этеп үк куйды.

Ә Анна үз тормышын сөйләде:

- Ирем ташлап чыгып киткәч, бу тормышта бөтен нәрсә сүнгәндәй булды, хәтта балаларымны да күрмәс хәлгә килдем. Мин аларны түгел, алар мине карадылар. Ә чиремне белгәч, иремне ничек тә кайтарырга, балаларымны ятим калдырмаска, дип аны эзли башладым. Ә ул инде өйләнгән булып чыкты. Аннан мин аңа үч итеп яшәргә, балаларымны аякка бастырырга, киләчәктә ач-ялангач утырмасыннар дип тырыштым. Хәзер минем үз сәүдәм бар, дөньям җитеш, балаларым яхшы уку йортларында укыйлар, ә аның инде миңа кирәге дә юк. Менә Илюшага рәхмәт, шул чакта миңа кул селтәгән булса, мин инде болай сезнең арада утыра да алмас идем. Балаларым кайда булыр иде хәзер, ә болай, Аллага шөкер, мин яшим, хәтта мин әле гашыйк та булдым бугай бер кешегә. Гомерем күпме калса, барысы да минеке, мин аның һәр көнен ләззәт табып яшим. Әле яратасы да, яратыласы да килә, шулай булгач, Рушания, борыныңны төшермә. Беләсеңме, минем үземнең матурлау салоным бар. Син шундый чибәр ханым, тик син шулай да бик төшенкелеккә бирелгәнсең, менә мин сине шушы салонга чакырам, эчең пошса кил, рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз. Аннан сине әзрәк бизәп җибәрү дә зыян итмәс, килештекме,- дип Рушаниянең кулына кулын салды.

Алар бик озак утырдылар, алар чыкканда инде көн кичләткән иде. Машинага утырыр алдыннан Рушания Ильяга карап торды да:

- Рәхмәт сезгә бу кичә өчен, мин аңладым сезнең ни әйтергә теләгәнегезне, - дип елмаеп хушлашты.

Юл буе ул Аннаның әйткәннәре турында уйланып кайтты. Кешеләрне күбрәк тыңлаган саен, Рушания үзен кабырчыгына төренеп яткан ташбака кебек хис итте, әле өч-дүрт ай элек кенә бу авыр язмышлы кешеләрне дә, андый куркыныч чирләр турында берни дә белми иде бит. Юк, белми түгел - ишеткәне бар, тик якыннан андый кешеләр белән аралашканы юк иде. Хәзер менә ул алар белән аралаша-сөйләшә торгач, аңлый, нинди авырлыклар кичергәннәр. Анна да, ялгыз калганы гына җитмәгән, әле ике кечкенә баласы, аларны көн дә туйдырырга, киендерергә кирәк. Көн-төн эшләп тә, очын-очка ялгый алмыйча үлеп киткән Хәлимә. Көчле дә соң бу хатын- кыз халкы, көчле булмый башка чарасы юк аның. Шулай да бернәрсә аңлашылмый иде: кая китә без җан аткан мәхәббәт, кая китә без Алла урынына күргән ирләр, ник соң ул мәхәббәтнең кала җимешләре генә, кая китеп югала соң мәхәббәтнең үзе? Һәрнәрсәнең үз кыйммәте, үз чагыштырмасы бар диләр, Рушания да үз тормышын аларныкы белән чагыштырды. Аның алай зарланырлыгы юк иде, балаларының тамагы тук, тату, матур гаиләдә үстеләр, киләчәкләрен дә әтиләре кайгыртып, җитеш тормыш әзерләп куйган. Үзе дә гомер буе балда-майда йөзеп яшәде. Әйе, мин бик озак бәхетле яшәгәнмен, Ходай кешегә әчесен да, төчесен дә татып карата, сират күперен кичәргә, күрәсең, миңа да чират җиткән.

Кичке кояш баер алдыннан Рушания койма буена килеп кулын кулга сугуга, янына тиеннәре килде.

- Килегез, кил, гөнаһсыз җан ияләре, сыйлыйм әле үзегезне. Рушания кесәсеннән чикләвекләр чыгарып сузды, олы тиеннәргә тагын ике кечкенә тиеннәр дә ияргән иде. - Ох, сезнең гаиләгез арткан икән бит, мин сезнең өчен бик шат, ой-ой, нинди нәниләр! Килегез-кил, курыкмагыз, монда барыгызга да җитәр. Ул чын күңелдән шатланып, матур күкрәк тавышы белән көлде, гөрләп сөйләште, ә тиеннәр аның кулына утырып сыйландылар, чикләвек ташыдылар. Бер кечкенәсе Рушаниянең иңбашына ук утырып алды, аңа шушы телсез җәнлек арасында әйтеп бетергесез рәхәт иде. Кинәт тиеннәре бөтенесе берьюлы урманга таба сикерделәр дә, юк булдылар.

- Туктагыз, кая ашыгасыз?

- Рая!

Рушания кинәт сискәнеп артка борылды, үзеннән ерак түгел генә торган ирен күреп, сискәнеп китте. Аны беренче күргәндәй, бераз аңа карап торды, әйтерсең, ул аны көтмәгән, акрынлап аның шат йөзеннән елмаю качты.

- Рая, Раечка, мин сине бөтен җирдән өзлим, ә син монда икән, - дип, Саша килеп Рушанияне кочаклап алды. Тик Рушания моннан тагын да ныграк куырылып, югалып калды, ни әтә, ни коча алмады. Борынына чит духи исе килеп бәрелгәч, чирканып куйды, әйтергә дип әзерләп куйган барлык сүзләре әллә кая югалды. Бар көчен учына җыеп, елмаерга тырышты.

- Бик озакладың, - дигән булды, йөзенә күтәрелеп карамыйча гына.

Элек булса, муенына килеп сарылыр, әрепләр төшер иде дә бит, юк шул, арада ниндидер күз күрмәс киртә барлыкка килде. Бәлки моны Рушания гына сизгәндер, ә Саша һаман берни булмагандай хатынны кочаклады, нидер сөйләде, тик Рушания берни ишетмәде, аңламады. Ничек шулай булдыра ала? Этеп җибәреп, «барысын беләм, син хыянәт итеп кайттың бит», дип кычкырасы килде. Юк, ул андый кеше түгел шул, ә ире бик тә бәхетле күренде. Рушания аны берсүзсез тыңлады, баш селкегән булды, тик иренең сөйләгәннәре ничтә башына барып җитмәде, аның үз уйлары башында кайнады. Шулай да Рушания акрынлап үз-үзен кулга алды, ничек тә түзәргә, тавыш - чыгармаска тырышты. Бер очы чыгар әле, ничек бар - шулай калсын дип, хәзергә сүз кузгатмаска булды. Бүгенге кичне алар элеккечә икәүләшеп үткәрделәр, улы фирмада җыелган эшләр турында сөйләде, кыскасы, ирләр сөйләштеләр, ә Рушания тыңлап кына тырыды. Астан гына ирен күзәтте: яшәреп киткәндәй тоелды, хәтта, ак чәчләре дә күренми - әллә буяткан инде? Эшләр харап болай чәчләр буята башлагач. Рушания кабат чирканып куйды, ире үзгәргән кебек тоелды, күзгә күз очрашмаска тырышты. Ул да, ахрысы, хатынының күзәтүен сизеп утырды. Элек булса, күзен алмас иде хатыныннан, ә бүген улы белән юкны бар итеп, эш турында гына сөйләште, һәрхәлдә, Рушаниягә шулай тоелды. Кинәт өстәлдә яткан кәрәзле телефон шалтырарга тотынды, Саша хәтта сискәнеп китте, ялт кына Рушаниягә карап алды. Буренен бүреге яна дигәндәй, үзе кып-кызыл булды, ә телефон сөрән салып һаман кычкыруын белде. Саша үрелеп сүндереп куйды, тукталган сүзне ялгап җибәрә алмыйча җәфаланды, улы да әтисенә сәерсенеп карап куйды.

-Кем ул, әти, нигә алмыйсың? – диде, эштәндер дип уйлап.

Элек әтисенең мондый гадәте юк иде, кемнән дә булса яшеренеп качып йөри торган, тик әтисе кул гына селтәде. Тик шалтыратучы тиз генә бирешәсе килмәде, кабат шалтыратырга тотынды. Саша өстәлдән телефонны алды һәм икенче бүлмәгә үк чыгып китте. Игорь аптырап бер әтисенә, бер әнисенә карап алды, әнисе башын аска иеп, каршындагы чәен болгата иде. Саша бик озак кына торып керде, Рушания башын күтәреп карамады, тик үзенең тәне кызыша, башы авырта башлавын тоеп, кесәсеннән даруын алып, күрсәтми генә кабып җибәрде. Ильяның уйланмаска, борчылмаска, тыныч булырга тырыш дигән сүзләре исендә, тик ул бит тере кеше. Кысып-кысып башы авырта иде, тик түзәргә кирәк, түзәргә. Саша уңайсызланып нидер аңлатып маташты, тик моны Рушания яхшы аңлый һәм шул ук вакытта аңламый да. Рушания авыр гына карашын өскә күтәрде, бермәлгә крепость кебек ныклы зур өйнең почмагы ярыла башлагандай тоелды, аннан ул акрын гына карашын иренә күчерде. Ярты сүз, бер күз карашыннан аңлашырга өйрәнгән кешеләр беренче тапкыр бер-берсен аңламадылар. Кич йокларга яткач та, Саша бик арыдым дип, артын күеп ятты. Элек булса, ул аны ашап бетерердәй була, яратып туя алмый иде. Бүген алар бер ятакта аерым-аерым һәркем үз уйлары белән, төн буе керфек тә какмый чыктылар. Бу хәл гадәти хәлгә әйләнә башлады. Саша кайчандыр үзе урнаштырган гаилә кагыйдәсен бик еш боза башлады, элек балаларына «кар яумагае, таш яуса да, кичке ашка сәгать җидедә өйдә булыгыз, анагызны көттереп утыртмагыз»,- дисә, менә хәзер үзе бик еш соңлап, кайбердә кайтмый да кала башлады. Хәзер инде өстәл артына җыелган авыр тынлыкны улы да сизә башлады, никтер ул да әтисенә башын бик күтәреп карамый, бик салкын гына сөйләшә. Ашыйлар да, өчесе өч якка тарала, сөйләшер сүз юк. Тизрәк ичмасам Алеся кайтсын иде, өйдә бу чаклы авыр тынлык тормас иде. Бөтенесенең өмете Алесяда иде. Ниһаять, көткән көн җитте, Алеся да кайтты. Ул үзе белән өйгә ямь алып кайтты, күбәләк урынына очты, әле берсен, әле икенчесен кочты- үпте, барысына да үзенең шатлыгын өләште, чикерткә урынына сикерде, шатланып көлде, ул да гашыйк, бәхетле иде. Кыз бала - кыз бала инде, кызы кайткач, Рушаниягә да җиңел булып калды. Рәхәтләнеп сөйләштеләр-серләштеләр, көндезләрен кияү балакай да килсә, өчәүләшеп бакчада чәй эчтеләр. Алмалар да өлгереп килә, ботакларын көчкә күтәреп утырган алмагачларга карап соклардылар. Айрат белән Алеся еш кына бакчада Рушания янында көннәрен үткәрәләр, берни яшермичә бик күп нәрсәләр турында уртага салып сөйләшәләр иде. Рушания балаларның аның янында булудан җан тынычлыгы, әйтеп аңлатыгысыз рәхәт таба иде. Айратны озатканда:

- Ешрак кил, Айрат, синең белән безгә бик күңелле, - дип елмая Рушания. Сөеклесе әнисенә ошауга Алеся да бик канәгать.

- Әйе шул, - дип әнисенә сыена.

Тик Айратның Алесяның әтисе белән генә очрашканы юк әле. Алеся чит илдән кайткач, беренче мәлдә мәхәббәтеннән башы әйләнеп, өйдә алай-болай берни дә сизмәде, тик әтисе соңлап кайта башлагач:

- Әти, нишләп болай соңлап кайта башладың, без бит сине ашарга көтеп утырабыз. Кичә мин сиңа шалтыраткач, телефоныңны ниндидер хатын-кыз алды, - диде.

- Секретаршадыр, - диде әтисе, кызарып.

- Әти, кесә телефонынмы, кичке ундамы?

Өйдә авыр тынлык урнашты, бөтенесе башларын аска иделәр. Бик авыр сорау иде бу. Рушания гына түгел, Игорь да бу сорауны биргәне юк иде әле әтисенә. Игорь, бәлки, нәрсәдер беләдер дә, тик Алеся гына бар да элекке кебектер дип уйлап, бөтенесен борчыган авыр сорауны кычкырып ярып салды. Аның башына да килми иде бу гаиләдә ни дә булса үзгәргәндер дип, аның өчен әтисе дә Алла, әнисе дә изге җан, башкача булу мөмкин дә түгел. Саша ни дә әйтергә белмәде.

- Ярый, балалар, башка соңга калмам, сез хаклы, кичке ашка соңга калырга ярамый.

Шуның белән сүз дә бетте. Саша вакытында кайта башлады, тик кичке ашны ашагач, юкны бар итеп чыгып китә дә, төн уртасында гына кайта. Рушания беркайчан да сорамады кайда булдың дип, тик арага кергән кара шәүлә генә зурайганнан зурайды. Утыз елга якын бергә йоклаган уртак ятак уртага бүленеп, аралар ерагайганнан ерагайды, суынды.

Рушания кабат больницага тикшерелергә килде, бу инде җәй азагы иде. Илья аңа карап торды:

- Рушания, ни булды сиңа, син чир белән бөтенләй дә көрәшмисең, шулай ук яшисең килмимени соң?

Рушания эндәшмәде. Оят иде кешенең тырышлыгына төкереп карау, тик үз-үзенә көче җитми башлады. Соңгы араларда Саша кунарга да кайтмый башлады, Рушаниянең моңа бик тә җаны әрни иде. Ул көн-төн ире турында уйлап башы катты, чирне бөтенләй уйламады, аны тик бер хәсрәт кенә басты - ул да булса Саша. Ул аның ярты җаны, ә ярты җансыз ничек яшәп була соң? Рушания чыгу юлын таба алмады, хәтта вакыт-вакыт тизрәк үлсәм иде дип хыялланды. Ә башта ак чәчләр артканнан артты, шулай да чибәрлеген җуймады. Илья аның анализларына карап баш селкеде, чирләр харап начар иде. Ничек йөри ул - башка сыймый, дип уйлады.

- Рушания, ашыкмасагыз, мине урамда көтеп тормассызмы? Мин хәзер чыгам.

- Яхшы, көтәрмен, - диде дә, ишеккә атлады. Рушания ишек төбендәге скамейкага килеп утырды, үз уйларына чумып, тирә-ягына әйләнеп тә карамады.

- Исәнмесез, сез дә монда ятасызмыни, ә мин сезне нишләптер доктор дип уйладым, сез мине хәтерлисезме?

Рушания бераз бу олы апага карап торды, кинәт йөрәгә “жу итте”.

- Сез мине тегә вакыт өйгә кайтарып куйдыгыз, мин рәхмәт тә әйтергә өлгермәдем, сез чыгып та киттегез.

- Ә, әйе, хәтерлим, иптәшегез ни хәлдә?

- Ярыйсы, иртәгә өйгә алып кайтам. Нишләрмен инде, үзем дә белмим.

Рушания бераз бу апага карап утырды.

- Күршегез кайттымы соң чит илдән, ул бәлки ярдәм итәр?

- Маринамы? Аңа без нигә кирәк, озакламый яңа фатирга күчәргә җыена. Теге карт сәяркәсе Яңа шәһәрдән фатир алып бирә ди.

Рушания кинәт шыбыр тиргә батты, аннан калтыранып куйды.

- Мин аңа бала табып бирәм дә, үземә өйләндерәм, ди.

- Ә аннан бала булмаса?

- Исең киткән, бала ясаучы беткәнмени.

Рушаниянең башы әйләнеп китте, егылмас өчен урындык артына тотынды, инде егылдым дигәндә, кемдер тотып калды. Рушания күрде, тик ишетмәде, гәүдәсе камырга әйләнде. Кабат күзләрен ачканда ул инде палатада иде, кулына ялганган энәләрне күз кырые белән генә күреп алды. Башында томан, битендә әллә нинди битлек кидерелгән, янында Илья утыра. Рушания кабат күзләрен йомды, тагын әллә йокыга талды, әллә аңын җуйды. Ул тагын ике көн больницада капельница астында ятты, бу юлы кесәсендә кесә телефоны шалтырап аны эзләүче булмады, чөнки ул аны бөтенләй үзе белән алмаган иде.

Дәвамы бар.

РЕКЛАМАЛАР ● БЕЛДЕРҮЛӘР ● КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ЯНВАРЬ АЕНА НАМАЗ УКУ ВАКЫТЛАРЫ

Көн дата	Сәхәр тәмам	Иртәнге намаз	Кояш чыга	Зәвәль тәмам	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	06:53	07:31	09:01	12:52	13:15	14:58	16:44	18:31
2	06:53	07:31	09:01	12:53	13:15	14:59	16:45	18:32
3	06:53	07:30	09:00	12:53	13:15	15:00	16:46	18:33
4	06:53	07:30	09:00	12:54	13:15	15:01	16:47	18:34
5	06:53	07:30	09:00	12:54	13:15	15:02	16:49	18:35
6	06:53	07:30	09:00	12:55	13:15	15:03	16:50	18:36
7	06:53	07:29	08:59	12:55	13:15	15:04	16:51	18:37
8	06:53	07:29	08:59	12:55	13:15	15:06	16:52	18:38
9	06:52	07:28	08:58	12:56	13:15	15:07	16:54	18:39
10	06:52	07:28	08:58	12:56	13:15	15:08	16:55	18:40
11	06:52	07:27	08:57	12:57	13:15	15:10	16:57	18:42
12	06:51	07:26	08:56	12:57	13:15	15:11	16:58	18:43
13	06:51	07:26	08:56	12:57	13:15	15:13	17:00	18:44
14	06:50	07:25	08:55	12:58	13:15	15:14	17:01	18:45
15	06:50	07:24	08:54	12:58	13:15	15:16	17:03	18:47
16	06:49	07:23	08:53	12:59	13:15	15:17	17:05	18:48
17	06:48	07:22	08:52	12:59	13:15	15:19	17:06	18:49
18	06:48	07:21	08:51	12:59	13:15	15:20	17:08	18:51
19	06:47	07:20	08:50	13:00	13:15	15:22	17:10	18:52
20	06:46	07:19	08:49	13:00	13:15	15:23	17:11	18:54
21	06:45	07:18	08:48	13:00	13:15	15:25	17:13	18:55
22	06:45	07:17	08:47	13:00	13:15	15:27	17:15	18:57
23	06:44	07:15	08:45	13:01	13:15	15:28	17:17	18:58
24	06:43	07:14	08:44	13:01	13:15	15:30	17:18	19:00
25	06:42	07:13	08:43	13:01	13:15	15:32	17:20	19:01
26	06:41	07:11	08:41	13:01	13:15	15:34	17:22	19:03
27	06:40	07:10	08:40	13:02	13:15	15:35	17:24	19:04
28	06:39	07:09	08:39	13:02	13:15	15:37	17:26	19:06
29	06:37	07:07	08:37	13:02	13:15	15:39	17:28	19:07
30	06:36	07:06	08:36	13:02	13:15	15:41	17:29	19:09
31	06:35	07:04	08:34	13:02	13:15	15:42	17:31	19:11

Графикны "Гани" мәчетенең имам - хатыйбы Рәхимҗан хәзрәт Фәйзуллин әзерләде. Белешмәләр өчен телефон: 89276317823.

МАГАЗИН «МИНДАЛЬ» ОБЪЯВЛЯЕТ НОВОГОДНЮЮ АКЦИЮ:
Игристые напитки - от 95 р,
Новогодние подарки - от 100 руб.,
Сахар - от 39 руб. 90 коп., картофель - от 13 руб. за 1 кг,
и другие товары к Новогоднему столу. В продаже также имеется отруби - 149 руб. за мешок;
Распорядок работы магазина «МИНДАЛЬ» по ул. Мусы Джалила, 14 а с 1 января по 7 января 2017 г. с 7 ч. 30 мин до 24 часов.
Цены действительны на день публикации. Спешите, количество товаров ограничено.
Адрес магазинов: ул. М. Джалиля, 14 А ул. Метро, 112.
Справки по телефонам: 2-20-35; 8-927-815-3000. 8-927-802-03-03.

Карагыз, кем килә?! Кызыл Әтәч килә икән бит!

2017 елда миллиардер да булмассыз, ач та тормассыз, бурычка да батмассыз.

2017 ел Кытай календаре буенча Кызыл Әтәч елы. Аны Тавык елы дип атау дөресрәк булыр. Ни өчен дигәндә, ягъни хатын-кыз башлангычы булып тора. Шуңа күрә ел аеруча хатын-кызлар өчен уңышлы булыр. Ут стихиясе хакимлек иткән актив тормыш позицияле, эшлекле туташ һәм ханымнар уңышка ирешәчәк. Кызыл Әтәч елы 2017 елның 28 гыйнварыннан башлана. Бу вакытка кадәр әле без Кызыл Маймыл хакимлеге астында яшибез.

Елның төп девизы – «Тыныч лык иң әйбәт сугыштан да яхшырак». Шуңа күрә бу елда компромисс мөнәсәбәтләр өстенлекле булачак. Ягъни кешеләр, сәясәтче һәм дәүләтләр бер-берсе белән дуслашу ягын эзләр.

Язга кадәр әле Әтәч үзен тыныч тотар, ә менә көннәр җылыта башлауга ук ул канатын җәеп үзен хуҗаларча тота башлаячак. Әтәчкә ваемсыз Маймыл хаталарын төзәтергә, тәртип урнаштырырга туры килер. Җәйгә таба Әтәчнең үзенең көтелмәгән сюрпризлары белән шаккаттырасы бар әле. Карьерада һәм бизнеста уңышка ирешергә теләүчеләргә күп эшләргә туры килер. Бу елда кызыклы контрактлар һәм тәкъдимнәр бик күп булачак. Иң мөһиме ашыкмаска һәм һәр адымны үлчәп ясарга. Әтәч күләгәдә утырып торырга яратмый, шуңа күрә бәйсезлек яратучыларны ярдәменнән ташламас. Эшен һәм яшәү урынын тамырдан үзгәртергә теләүчеләрне дә Әтәч үз итә.

Акча мәсьәләсендә дә тотрыклылык булыр. Миллиардер булмасагыз да, ач тормассыз, бурычка да батмассыз. Бары ялкауланмаска гына кирәк. Уңыш үзе сезне эзләп табар. Гаиләле кешеләрнең тормышы җайланып китәр. Бу елда туган балалар бик талантлы булыр. Алардан танылган язучылар, сәясәтчеләр һәм артистлар чыгарга мөмкин. Нәтиҗәдә Әтәч елында кешеләрнең хыяллары чынга ашып, тормышлары матурланыр!

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, Иске Кулаткыдан "сугыш елы баласы", хезмәт ветераны **Тәүхидә Исхаковна УСМАНОВАНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Стоматология ООО «Дента Люкс»

приглашает вас воспользоваться качественными услугами современной стоматологии
пациентам нуждающимися в протезировании готовы предложить:
- съемное протезирование: протезы из акриловых пластмасс, бюгельные, нейлоновые;
- несъемное протезирование: коронки с покрытием, металлокерамические, комбинированные, цельнолитые и.т.д.

Запись предварительно по тел.: 89278033404, Пионерская, 18 А. Консультация бесплатно.

ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА
Производство и установка пластиковых окон.
При заказе пяти окон, шестое – бесплатно!
Замер, доставка – бесплатно.
Наше качество и доступные цены порадуют вас! Пенсионерам – дополнительная скидка!
20% скидка

Телефон: 8-937-278-05-55.
Павловка.

В ООО «ТЭК УДАЧА» требуются: водитель – экспедитор на а/м, междугородние перевозки, механик по ремонту автотранспорта. Обращаться по телефону: 89278115136.
Заработная плата при собеседовании. Опыт работы обязателен.

В р.п. Старая Кулатка продается: живые, белые индюки весом 10-12 кг., живые петухи – 400 руб., молодые петушки – 300 руб. за штуку, подсолнечник – от 20 руб за 1 кг., домашняя капуста – 18 руб. за 1 кг., квашеная капуста – 70 руб. за 1 кг.,красная свекла – 20 руб. за 1 кг., тыква – 10 руб. за 1 кг., а также дрова – недорого. Телефон: 89084801686.

Утерянный аттестат о среднем общем образовании на имя Хуснутдинова Рината Ибрагимовича считать недействительным.

Скорая компьютерная помощь
ИП «Шафиева» предоставляет услуги по установке, настройке, а также по ремонту компьютерной технике. Профессиональный ремонт компьютеров и ноутбуков.
Установка WindowsXP/7/8/10; Удаление вирусов, установка антивирусника; Очистка от пыли и грязи при перегреве; Оптимизация работы компьютера и многое другое. Выезжаю в села, работаю с организациями. Цены приемлемые. Действует скидочная система. Заказы принимаются круглосуточно.
Мы находимся по адресу: р.п. Старая Кулатка, в здании магазина «Магнит» на втором этаже, павильон № 12.
Звоните по телефону: 89279837788 (Марс).

БУРЫЧЛАР КИТАБЫ



«Маймыл елы» китеп «Әтәч елы» килер алдыннан, декабрь урталарында, Иске Кулаткы эшчеләр поселогындагы «Миләүшә» магазинының бурычлар китабын урладылар. Бу хәл сатучыларның күңелендә зур борчу, кибет хуҗасы Зөләйханың йөрәк түрендә сатучыларга карата нәфрәтле ачу тудырды.

«Табыгыз! Җир астыннан булса да табыгыз! Китапны, тапмасагыз, үзегезгә гаепләгез, эш хакыгыз да, «Кыш бабай» дан бүләкләр дә юк сезгә!!! - дип кычкырынды сатучылар өстенә .

Кызлар куркуга калып, китап югалудан гаеп эзләп, бер-берсе белән әрләштеләр. Китапханәдән алып укый торган китап югалган булса бер хәл, аның икенче экземплярын табып була, ә бу бурычлар теркәгән бердәнбер, мал хисабын алып баручы әйбер бит .

Эх, бу халыкның акчага кытлык кичерүе!!! Маллары булса,бу китапны ачмаган да булыр идек, - дип зар кылдылар кызлар. Хәзер инде кемнең бурычка нәрсә алганын ничек исеңә төшерәсең, кем генә юк бит анда, - дип алар әҗәткә әйбер биргән кешеләрнең исемлеген хәтергә төшерергә газапландылар. Ләкин, файдасыз. Кем нәрсә алгандыр? Кем кайчан алгандыр? Кем нәрсә эчкәндер? Шайтан белсен!!! Юк бит! Юк! Бурычлар китабыннан гына белеп була моның турында.

"Маймыл елы"ның соңгы көннәре сатучы кызларны зур хәсрәткә салды, әйтерсең Маймыл үзе бу китапны урлаган да һәм озакламый урманга качып китәр кебек тоелды. Ә кибет мөдире Зөләйха, йомшаклык күрсәтмичә, көннән-көн нәфрәтләнә

Менә шулай "ут эчендә" янып, китап табылыр дигән өмет белән 31 декабрь дә килеп җитте. Ис итмәгәндә Яңа ел - «Әтәч елы» керер алдыннан, «Миләүшә» кибетенә Кыш бабай белән Кар кызы, хәтта Әтәч тә килеп керделәр.

Кикрикүк!!! Кикрикүк! – шатланыгыз, бурычлар китабыгызны «Кәкре Җамал» тыкрыгыннан таптык ,– дип әтәч китапны Кыш бабайның капчыгыннан алып, кибетнең мөдиренә тоттырды.

Инде моны күреп, бу хәбәрне ишеткәч, сатучы кызларның шатлыклары "эчләренә сыймады", куанычтан алар кибетнең түшәменә кадәр сикерделәр, бер-бересен кочып үптеләр. Кибет мөдире Зөләйханың да кәефе күтәрелде. Ул кызларны гафу иткән күк, шул ук минута Кыш бабай белән Кар кызының кулыннан Яңа ел бүләкләре өләштерде һәм эш хакларын тапшырды.

Озак та үтми сәгать 12 не сукты, сатучы кызлар шампан тутырган бокалларны чәкәштереп, елмаешып, бер-бересен 2017 ел «Әтәч елы» белән кайнар тәбрикләделәр һәм якты теләкләрен әйттеләр. Аларның йөзе чиксез шатлык белән тулы иде.

…Тик бу вакытта китапның битләрендә урлаучылар тарафыннан - "бурычлары түләнгән",- дип барлык исем-фамилияләрнең сызылып ташланулары турында беркем дә белми иде әле.

Рәстәм АРИФУЛЛИН.

Директор-баш редактор М.С. Масиева.

Адрес редакции, издателя: 433940 р.п. Старая Кулатка Ульяновской области, ул. Куйбышева, 22. ОАУ Редакция газеты "Кумяк кюч".

Телефоннар:
электрон адрес: kumiakk@mail.ru
884(249)2-11-94-редактор, факс, бухгалтерия;
884(249)2-12-64 - журнали - стлар, реклама бүлеге, РИК операторлары.

Индекс 54505.
Газетаны басарга кул кую вакыты: график буенча - 16.00
фактта - 16.00
Тираж 2600
Заказ № 13/52
Распространяется по подписке.

Газета отпечатана с готового оригинала-макета в ООО «Принт Хаус» 432071, г. Ульяновск, ул. Федерации, 15.

Элемтә һәм масса - күләм коммуникацияләр сферасында күзәтү буенча Федераль службаның Ульяновск өлкә идарәсе 2014 елның 21 ноябрендә ПИ №ТУ73-00388 номерлы масса-күләм информация чарасын регистрацияләү таныклыгы белән регистрацияләнде.

Газета битләренә урнаштырылган рекламалар һәм белдерүләр өчен редакция җаваплылык тотмый.

Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Хатлар, кулъязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.